Сезгә күпме тиешләр?

Бу темага еш язсак та, пенсия түләү буенча мөрәҗәгатьләр шактый килде. Стаж һәм балларны ничек исәпләргә? Пенсия билгеләр өчен нинди документлар кирәк? Бу өлкәдә нинди үзгәрешләр көтелә? Укучыларыбыз сорауларына Россия Пенсия фондының Татарстан бүлеге идарәчесе Эдуард ВАФИН аңлатма бирде.

5 БИТ

Кәркәле таулары биек...

Айдар Галимовның туган авылында кунакта

8 БИТ

1990 ЕЛДАН БИРЛЕ ЧЫГА

Шәһри КАЗАН

татмедиа

Пәнҗешәмбе | 9.02.2017 | № 13 (5775)

www.shahrikazan.com

ТАТАРСТАН БАШКАЛАСЫНЫҢ КӨНДӘЛЕК ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ҺӘМ МӘДӘНИ ГАЗЕТАСЫ

САК ЙӨРЕГЕЗ ЗУР ЮЛЛАРДА!

Узган атнада бер-бер артлы кайгылы хәбәрләр килеп торды. Транспорт һәлакәтендә журналист Эльвира Ибраһимова (күпләр аны Мотавалова дип белә) һәлак булды. Аның белән якыннан таныш булганнар, ягымлы тавышын тыңлап, күңелләренә тынычлык алган радио тыңлаучылар айнып җитәргә, тын алырга да өлгермәде, икенче көнне үк тагын бер фаҗига турында хәбәр килеп ирешә. Минзәлә театры актрисалары Эльмира Әхмәтханова белән Эльмира Гәрәева М-7 трассасында һәлак булган...

6-7 БИТ

mapio.net

П2430 Атналык (пәнҗешәмбе)

1 айга — 65 сум 73 тиен
3 айга — 193 сум 19 тиен
6 айга — 394 сум 38 тиен

Ташламалы бәядән языл кал!

һәр айның **15** числосына кадәр язылсагыз, газета киләсе ай башыннан киләчәк

Синең өчен, Синең турында!

П2395 Көндәлек (сишәмбе, пәнҗешәмбе, җомга)

120 сум 27 тиен — 1 айга
387 сум 81 тиен — 3 айга
775 сум 62 тиен — 6 айга

РЕСПУБЛИКАДА

АЗНАКАЙ

Азнакайда, ялгызларны парлы итү максатында, мәдәният йортларында «Пар канат»лар клубы аеруча актив эшли башлаган. Күптән түгел Үчәлле авылында Кино елына багышлап фестиваль уздырганнар. Биредә төрле авыллардан җыелган ялгызлар рәхәтләнеп күңел ачкан, табын артында аралашкан. Киләсе очрашу – «Чәй» фестивале Туйкә авылында булачак. 14 февральдә исә Мәнәвез авылы клубында барлык ялгызлар өчен «Әйдә өйләнешәбез!» исемле чара узачак.

АЛАБУГА

Алабуга дәүләт музей-тыюлыгында «Дөнья курчаклары» дигән уникаль уенчыклар күргәзмәсе эшли. Анда 100дән артык илдән 278 экспонат тупланган. Биредә япон фарфор курчаклары, борынгы антропоморф фигуралары, мистерия һәм театр курчаклары да бар.

ӘЛМӘТ

11 февральдә Әлмәттә «Татарстан чаңгы юлы» массакүләм ярышы узачак. Быел чарада җылынып өчен чәй эчү нокталары, уен мәйданчыклары да булдырырга уйлыйлар. Чаңгы ярышларында студентлар, мәктәп укучылары гына түгел, пенсионерлар да катнашыр дип көтелә. Әлеге ярыш Әлмәттә беренче генә ел уздырылмый. Былтыр барлыгы 23 меңнән артык әлмәтле чаңгыда чыккан булган. Быел катнашучылар тагын да күбрәк булыр дип көтелә.

САБА

Саба районында «Каймак» дип исемләнгән сөт эшкәртү комбинаты ачарга җыеналар. Әлегә «Каймак» хуҗалыклардан көненә 9 тоннага якын сөт җыя. Әмма җитештерү җайланмалары булмаганга, аны Саба сөт комбинатына тапшырырга мәҗбүр. Яңа җитештерү цехы ачылганнан соң биредә ике сменада 3әр тонна сөт эшкәртү күздә тотыла. Киләчәктә авыл хуҗалыгы кооперативы катык, майлы һәм майсыз эремчек, тиз өлгерә торган «Адыгея» һәм «Брынза» сортлы сырлар җитештерергә планлаштыра.

Яңалыклар район газеталары сайтларыннан алынды.

Татарстан Президенты Согуд Гарәбстанында

Согуд Гарәбстанына эшлекле сәфәре кысаларында, Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов Согуд Гарәбстаны Короле Салман бин Абдел Азиз Әль-Согуд белән очрашты. 2015 елда Согуд Гарәбстанына Россия Президенты Владимир Путин барган иде. Шул чакта ук ул Корольне Россиягә чакырган булган. Рөстәм Миңнеханов исә, аңа Владимир Путиннан сәламнәр җиткереп, Россиягә визиты турында исенә төшерде, Татарстанга да кунакка дәште. Король исә чакыруны җавапсыз калдырмады, җылы вакытта килергә вәгъдә итте.

tatarstan.ru

Очрашу барышында Рөстәм Миңнеханов Татарстанның икътисади хәле, сәнәгать өлкәсендәге үсеш, партнерлык банкингы системаларын Ислам законнары нигезендә эшләтү турында сөйләде. Президент фикеренчә, Россиянең һәм Ислам илләренең икътисади хезмәттәшлеге өчен төп мәйданчык булып KazanSummit халыкара форумы тора. Ул Согуд Гарәбстаны делегациясен май аенда узачак чираттагы форумга чакырды. Татарстанның кунакларга күрсәтерлек казанышлары җитәрлек, уртак хезмәттәшлекне ныгыту өчен дә мөмкинлекләр тудырылган.

– «Безнең «КАМАЗ» автомобильләре Париж-Дакар раллиенда даими җиңә, шулай ук илегезне вертолетлар, авыр йөк суднолары, нефть химиясе продукциясе, минераль ашламалар, нефть-газ җиһазлары, суыткыч техника, азык-төлек һәм авыл хуҗалыгы товарлары, һәм Татарстанда җитештерелә торган башка товарлар белән дә тәэмин итәргә әзер, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Сүз уңаеннан искәртеп узыйк: Татарстан Президенты «Россия – Ислам дөньясы» стратегик караш төркемен җитәкли. Төркем эшчәнлегенең төп максаты – дәүләтләр һәм халыклар арасында үзара аңлашуны һәм ышанычны ныгыту, экстремизм һәм терроризм идеяләрен таратуга каршы тору. Җиддә шәһәрендә Ислам хезмәттәшлеге оешмасы Генераль секретаре Йосыф бин Әхмәд Әль-Осеймин белән сөйләшкәндә дә Рөстәм Миңнеханов дөньяда тынычлык һәм татулык булмаган төбәкләр өчен борчылуын белдерде. Владимир Путинның Якын Көнчыгышта тынычлык урнаштыруга аерым игътибар бирүенә дә басым ясады. Йосыф бин Әхмәд Әль-Осеймин исә Татарстанда дөньяның барлык дин вәкилләре дә тату яшәгәнлеген искәртте.

Сәфәр кысаларында Рөстәм Миңнеханов кече хаҗ-гомрә кылган. Аның белән бергә Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин да хаҗ йолаларын үтәгән. Мәккәдә дин тотучы Кәгъбәгә карап, Аллаһ Тәгаләдән хаҗының кабул булуын сорап дога кыла. Кәгъбә эчендә булу гадәттән тыш сирәк өстенлек санала. Мондый мәртәбә Президентка насыйп булган.

Эшлекле сәфәр «Татарстан – Согуд Гарәбстаны» дип исемләнгән бизнес-форум белән тәгәлләнде. Россиянең Согуд Гарәбстанындагы Гадәттән тыш һәм тулы вәкаләтле илчесе Олег Озеров үз чыгышында, Татарстанның Россиядә иң алга киткән төбәкләрнең берсе булуын искәртеп, икътисади потенциал гарәп бизнесын кызыксындырырга тиеш дигән фикерен җиткерде.

Президентның сәфәрен Согуд Гарәбстанындагы матбугат та киң яктыртып бара. Рөстәм Миңнехановның фотолары җирле басмаларның беренче битендә урын алган. Бизнес-форумнан соң да Президент журналистларга интервью биргән.

Шәһәр кәефе

РӘИС ШӘРӘФИЕВ,
пенсионер:

– Кенәр авылы элек Тукай районы үзәге иде, мин шуннан үзем. Казанда 1964 елдан яшим. Кыш ялыктырды, җәйне һәм бакчаны сагынам. Курдюмов ысулларын кулланам, белгеч Фарсель Зыятдинов китапларындагы киңәшләргә таянам. Мәсәлән, гап-гади миләш үсентесен җир өстеннән ун сантиметр биеклектә тулысынча кисеп, шуңа алмагач ботагы ялгасаң, ул алмагач булып үсә.

ГӨЛНАЗ МИННЕХАНОВА,
хезмәткәр:

– Баулы районы кызы мин, Казанда 2011 елдан. Майлы буяулар белән рәсем ясарга, чигәргә яратам. Бер шәмаилне, тәфсилләп, ярты ел дәвамында чиктем. Һиндстанга барып кайтырга хыялым бар. Мәчеткә йөрим, ислам дине гыйлемнәрен өйрәнәм. Казанда элеккеге «Пионерлар йортлары» кебек учреждениеләр күбрәк булсын иде. Балалар аларда, бернинди түләүсез, сәләтләрен үстерсен иде.

РАИЛӘ МОТЫЙГУЛЛИНА,
журналист:

– Северный бистәсендә юллар төзелә башлады, шуңа сөенәбез. Алга таба кече урамнарга да асфальт яки таш түшәлсен иде. Северный бистәсендә балалар уен мәйданчыгы юк дисәң дә була. «2нче кибет» тукталышы зонасында уен мәйданчыгы төзү кирәк. Кулга кайчан чигү тотканымны хәтерләмим дә инде, бөтен вакыт балалар һәм оныклар белән уза. Җиңел автомобильдә Европа буйлап сәяхәт итәргә дип планлаштырып торабыз.

АЙГӨЛ ФАЗЫЛҖАНОВА,
хезмәткәр:

– Казанда яши башлаганыма – тугыз ел, тумышым белән Балтач районыннан. Кышкы талчыгуны бетерер өчен даими рәвештә бассейнга йөрим. Тәнгә су искиткеч ял бирә. Урамда салкын, ә бассейнда йөзгәндә үзеңне җәйдә шикелле хис итәсең. Метрода йөрергә бик яратам. Метро халык күп яши торган Азино тарафларын колачласын иде. Берләшкән Гарәп Әмирлекләрендә булганым юк әле, җәйге сәяхәтем, мөгаен, шунда булыр.

ОЛЕГ ЛЕВИН,
отставкадагы хәрби:

– Казандагы элеккеге Ленин районында туып-үстем. Ул хәзергә Яңа Савин белән Авиатөзелеш районнары. Кышын ял көннәрендә кораблар макетлары җыям. Бу шулкадәр мавыктыргыч шөгыль. Түтәлдә казынырга яратмыйм, агач-таш эшләре күңелгә якынрак. Казан читендә өй төзергә кирәшкән идек, шуны ничек тә тәмамлап чыгасы бар. Кешеләр башкаларга карата битараф булмасын иде.

Халык зарланырга өйрәнде

2007 елда Татарстанда Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеген саклау өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенә (Роспотребнадзор) үз хокукларын яклауны сорап, 1283 кулланучы мөрәҗәгать иткән булса, 2016 елда аларның саны 8233кә җиткән. Иң активлары – Казан һәм Түбән Кама халкы. Республика районнарына килгәндә, Спас районында яшәүчеләр дә үз хокукларын яклый белә.

Дилбәр ГАРИФУЛЛИНА

Роспотребнадзорның Татарстан идарәсе җитәкчесе урынбасары Марина Трофимова сүзләренчә, элек халык күбесенчә товарның сыйфатыннан гына зарланса, соңгы елларда алынган мөрәҗәгатьләрдә хезмәт күрсәтүдән канәгать булмаучыларның саны артуы күзәтелә.

– Безгә мөрәҗәгать итүчеләрнең 60 проценты – торак-коммуналь хуҗалык, финанс, көнкүреш һәм элемтә хезмәтләреннән зарланучылар. Аеруча матурлык салоннары, чәчтарашханәләрдән күп зарланалар. Сәүдә өлкәсенә килгәндә, мөрәҗәгатьләрнең 42 проценты техник товарларның сыйфаты белән бәйле. Сатучылар гаджет, көнкүреш техникасын ремонтлаудан баш тарта яки аның срогын кичектерә, яраксыз товарны яңасына алыштырудан баш тарта, акчаны кайтармый. Интернет кибетләрдән, иминият компанияләреннән, микрофинанс оешмаларыннан зарланучылар да артты, – дип сөйләде ул матбугат очрашуында.

2016 елда ведомство хезмәткәрләре ярдәмендә татарстанлылар суд аша 14,5 миллион сум акчаларын кайтарган. Хокук яклаучыларга, милеккә кагылышлы бәхәсләрне чишүне сорап, 478 тапкыр судка мөрәҗәгать итәргә туры килгән.

Аерым очракларга килгәндә, респу-

vk.com

блика халкы «Много мебели» бренды астында эшли торган кибетләрдән күп зарлана. Әлеге кибетләр район җирлекләрендә дә бар. Аларны шәхси эшмәкәрләр ачкан.

– Бер эшмәкәрдән зарланып йөз мөрәҗәгать кабул ителде. Ул товарны йә вакытында китермәгән, яки аның урынына башкасын җибәргән. Икенче бер эшмәкәргә 36 тапкыр штраф язылды. Штрафларның күләме зур түгел, әлбәттә, шуңа да ул тиз генә төзәлергә ашыкмый, – ди Марина Трофимова.

Роспотребнадзорга мөрәҗәгать итүчеләрнең артуы кулланучыларның грамоталыгы арту белән бәйле. Узган елны 17 мең кеше консультация алган, матбугат чараларында 2 мең мәгълүмати материал бастырылган, 13 мең кешегә лекция укылган, 11 тапкыр «кайнар линия» оештырылган.

Сүз уңаеннан, үткән елны Татарстан кулланучылар союзына 3032 кеше мөрәҗәгать иткән. Сөт продукциясе, кондитер һәм казылык эшләнмәләренең сыйфатыннан зарланучылар күп. Кесә телефоны, мебель, автомобиль, ишек, пластик тәрәзә, аяк киеменең сыйфаты да ышаныч тудырмаган. «Ашан» гипермаркетын тикшерү барышында ярмаларның ярлыгында җаваплы кешенең имзасы һәм оешма пичәте булмавы ачыкланган. Товарга бәя бертөрле куелган, кассада икенче бәя күрсәткән очраклар да булган. Тутырып куелган товарларның авырлыгы күрсәтелгән саннардан 8-10 граммга азрак булып чыккан. «Астория» рестораныңда да җитешсезлекләр табылган. Анда тәкъдимнәр китабы юклыгы ачыкланган. Продукциянең составы, калорияләре турында язылмаган мәгълүматлар дөрес түгел. «Monigue» матурлык салонында һәм «9 месяцев» клиникасы эшчәнлегендә дә җитешсезлекләр булган. «Стоматология – Дэнс+» клиникасы инвалидлар өчен пандус урнаштырмаган.

ТОП – 3

БЕР атна эчендә Татарстанда кискен тын юллары вируслы инфекциясе һәм грипп белән авыруның 26729 очрагы теркәлгән. Бу, узган атна белән чагыштырганда, 5,3 процентка күбрәк дигән сүз. Табиблар фаразлавынча, эпидемия алдагы еллардагы кебек үк бара. Тик менә февральдә грипп белән авыручылар саны сизелерлек артырга мөмкин, ди.

БУШЛАЙ торакны хосусыйлаштыру мөмкинлеге 1 мартта төгәлләнергә тиеш иде. Әмма аны 2020 елга кадәр озайтырга булдылар. Дәүләт Думасында беренче укылышта бу яңалык бары кырымлылар, ятимнәр, тузган торакларда яшәүчеләргә генә кагыла диелсә, икенче укылышта закон проектына үзгәрешләр кертелеп, ул бар кешеләр өчен дә озайтылды.

РОССИЯ Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан буенча Баш идарәсе Татарстанда яшәүчеләрне, 10 февральгә кадәр һава торышы начарлану сәбәпле, куркынычсызлык кагыйдәләрен истә тотарга кисәтә. Температураның бу көннәрдә климат нормасыннан 7-12 градуска түбән төшүе бар. Бу уңайдан республикада ике мобиль җылыну пункты да урнаштырылды. Аның берсе – Казан – Оренбург трассасының 250нче чакрымында Әлмәт районында, икенчесе М7 трассасының 1006 нчы чакрымында Алабуга районында куелган. Юлларда бозлавык, буран булуы ихтимал. Шуңа да ерак юлга чыгуны кичектереп торырга киңәш ителә.

Кыйный, димәк, яратамы?

Россия Президенты Владимир Путин гаиләдә кыйнаулар очрагы беренче тапкыр теркәлгәндә, аны җинаять дип түгел, ә административ хокук бозуга кертеп карау турында законга кул куйды. Икенче һәм аннан соңгы очракларда ул җинаять дип танылачак. «Кыйнаулар» дип закон сәламәтлеккә зур зыян китермәгән физик авыртуны күздә тота. Сүз кара янган урыннар һәм тырналган яралар турында бара, сәламәтлеккә зыян килгән очраклар җинаять дип табылачак. Әлеге закон турында сезнең фикерегез нинди?

Наилә БӘШИРОВА, психолог:

– Миңа калса, бу закон һәр яктан уйлап эшләнгән. Гаеп атта да, тәртәдә дә бар, диләр. Ул, чынлап та, шулай. Хатын-кыз үзе үк ир-атны кул күтәрүгә этәрергә мөмкин. Гадәттә, хатыннар милициягә барып гариза яза да аннары бу адымына үкенә башлый. Өйдә бәхәс буш урыннан гына чыкмый, үзара аңлашу булмаса, психологларга мөрәҗәгать итәргә кирәк. Беренче кисәтүдә үк аңламаган ирне, кул күтәрүләрен дәвам итсә, җинаять җаваплылыгына тарту кирәк, әлбәттә. Югыйсә бу аның өчен гадәтигә әйләнеп китәргә мөмкин.

Нияз хәзрәт САБИРОВ, «Апанай» мәчете имам хатыйбы :

– Пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.с.): «һәрбер кеше – хаталы. һәм иң хәерле, мактаулы хаталанучылар – хаталарын танып, аңлап төзәтергә теләүчеләр», – дигән. Ир-ат ялгышырга да мөмкин, әмма хатасын башка кабатламаска тиеш. Икенче бер хәдисендә: «Мөэминнәр арасыннан иң камил иманлылары – күркәм холыклы булганнары, ә арагыздан иң хәерле булганнарыгыз – үз хатынына карата күркәм мөгамәләдә, яхшы мөнәсәбәттә булганнарыгыздыр». Әлеге хәдисләр – гаиләдәге мөнәсәбәтләрне яхшырту, кул күтәрүләрне булдырмас өчен менә дигән вәгазь.

Айсылу КӘРИМОВА, укытучы:

– Күп кенә хатын-кызлар, ирләренә карата җинаять эше ачыла дигәч, куркып калалар. Аларны йә кызганалар яки балаларының киләчәгенә тәэсир итәр, диләр. Шуңа да гариза язарга ашыкмаячаклар. Шуның белән үзләрен куркыныч астына да куялар. Димәк, башта административ җаваплылыкка тарту дөресрәктер.

Акча бурлары токтарланды

«Татфондбанк» тирәсендәге вазгыятьне ачыклау дәвам итә. 6 февральдә Татарстан буенча Эчке эшләр министрлыгының Баш тикшерү идарәсе хезмәткәрләре «Татфондбанк» төркемәнә керә торган «ТФБ Финанс» директоры Тимур Вальшинны кулга алды.

Икенче көнне үк, акча урлауда шикләнеп, тагын ике кешене токтарладылар. Аларның берсе – «ТФБ Финанс» инвестиция компаниясенең актив операцияләр идарәсе башлыгы, икенчесе – клиент сервисы буенча җитәкчесе. Икесе дә «Татфондбанк»ның кыйммәтле кәгазьләр базары өлкәсендә дә эшләгән.

Клиентлар әйтүенчә, «Татфондбанк»та 1 миллион сумнан артыграк кертемнәре булганнарга, июнь аеннан октябрьгә кадәр, акчаларын банкның бүлендегә булып исәпләнгән «ТФБ Финанс» инвестиция компаниясенә күчерергә кушканнар. Әмма кертемнәрнең иминиятләштерелмәячәген алардан яшергәннәр. Нәтиҗәдә, еллык ставканың шактый югары процентларына кызыгып, күпләр «ТФБ Финанс» инвестиция компаниясенә күчкән. Араларында пенсионерлар да бар. Бүген Татарстанның эчке эшләр органнарына клиентлардан акча урлау турында 100дән артык гариза килгән.

Тикшерү барышында «ТФБ Финанс» оешманың офисында тенту үткәрелгән, бик күп документлар кулга алынган. «ТФБ Финанс»ка карата «Аеруча зур күләмдә алдау» маддәсе буенча җинаять эше кузгатылган. Исәпләүләр буенча, кертемчеләргә килгән зыян күләме 90 миллион сумнан артык. Тикшерү эшләре дәвам итә.

АТНА ФОТОСЫ

Илдар Мөхәммәтҗанов фотосы

Вәлиевләр өй туе көтә

Редакциягә Самосырово бистәсеннән Илсөяр апа Вәлиева мөрәҗәгать итте. «Йортыбызда кайнар су юк, бәдрәф урамда, канализация эшләми. Ирем белән үзем бер хәл, балаларга авыр. Алар безнең сигезәү. Иң олысына – 26, иң кечкенәсенә 4 яшь. Торак шартларыбызны яхшыртуны кайчанга кадәр көтәргә туры килер икән?» – дип сорый укучыбыз.

Илдар Мөхәммәтҗанов фотосы

Эльвира МОЗАФФАР

Без килгәндә, Илсөяр апа өйдә юк иде. Балаларының кайсысын мәктәптән, кайсысын балалар бакчасыннан алырга киткән икән. Ул да түгел, йорт алдына җиңел машина килеп туктады. Машинадан ир белән хатыннан тыш, бер-бер артлы биш бала төшкәнне күреп гаҗәпләнеп калдык.

– Ә нишләргә соң? – диде хуҗабикә, безнең сораулы карашыбызны күреп. – Өч кешелек урынга бишесен тыгызлап утыртам инде. Зур машина алырга мөмкинлегем юк. ЮХИДИ хезмәткәрләре туктата инде, штраф та салалар. Кечкенә сабыйларны өйдә үзләрен генә калдыра алмыйм бит…

Өйгә узабыз. 60 квадрат метрлы йортта ун кеше яши. Илсөяр Вәлиева күптән түгел Республика психиатрия хастаханәсендә кече шәфкать туташы булып эшли башлаган, иренең даими эше юк. Ике олы малай хәрби хезмәттән кайткан, эшкә урнашканнар. Буй җиткән кызлары колледжда пешекче белгечлеген үзләштерә. Өч бала мәктәптә укый. Икесе балалар бакчасына йөри.

Малайларга, кызларга аерым киенеп чишенү урыны булсын өчен, Вәлиевләр йортны бүлеп чыкканнар. Дөрес, бүлмәләрнең кайберләренә ут кермәгән. Кухняны юыну бүлмәсе һәм бәдрәфкә әйләндергәннәр. Өйгә су кергән, тик кайнар су юк. Залда идәнгә утырып ашыйлар, шунда дәрес тә әзерлиләр, йоклыйлар да.

– Өстәлне махсус куймыйм. Ун кешегә зур өстәл кирәк, ә ул бөтен бүлмәне алып торачак. Йөрергә дә урын калмый, – ди Илсөяр апа.

Баштарак Вәлиевләр Глушко урамында фатирда яшәгәннәр. Ишле бала белән шәхси йортта яшәү уңайлырак булыр иде дип Совет районы хакимиятенә мөрәҗәгать иткәч, аларга Самосырово бистәсеннән йорт биргәннәр.

– Үз бакчабыз булыр, балалар туйганчы яшелчә, җиләк-җимеш ашарлар дип хыялландык. Юкса, бер кило алма алсаң, балаларга берешәр дә тими, – диләр.

Карап торышка йорт начар түгел. Вәлиевләр үзләре дә аны матурларга, уңайлы итәргә тырыша. Чиста да. Аларны аның кечкенә булуы һәм барлык уңайлыклар булмавы гына борчый. Йортны төзекләндергән дә булырлар иде, тик үзләрен кәкре каенга терәткәннәр. Илсөяр Вәлиева бер өлеш җир участогын сатудан кергән акчаны, башка керемнәрен – барлыгы 1 миллион сумнан артык акчаларын «Рост» кредит оешмасына салган. Акчаларын берничә тапкырга арттырып алырга хыялланган. Тик бу «финанс пирамидасы» булып чыккан. Татарстанның Эчке эшләр министрлыгы хәбәр итүенчә, әлеге оешмадан 3000нән артык кеше алданган. Гомуми зыян суммасы – 850 миллион сум.

– Бу вакыйганы бик авыр кичердем. Үземә кул салырга да уйладым. Аннан гаиләм өчен яшәргә кирәклеген аңладым. Ярдәм сорап җитәкчелек бусагасын таптый башладым, – ди сигез бала анасы.

Ул балаларын ияртеп, плакатлар язып, урамга да чыга. Татарстан хакимияте, күп балалы ананың хәленә кереп, ярдәм йөзеннән 1 миллион сум акча бүлеп бирә. Совет районы хакимияте мунча төзетә.

– Ирем белән икебезнең айлык керем 25 мең сумнарга җыела. 1900 сум тирәсе субсидия алабыз. Тик ашау-эчүгә генә дә көн саен диярлек 2 мең сумлап тотыла. Көнәнә ун буханка ипи, җиде-сигез күмәч китә. Ун литр сөт, май, токмач… Ярый әле «Бәхетле» социаль ашханәсе ризык белән тәэмин итә башлады. «Зәкят» фонды киемнәр бирә. Торак-коммуналь хезмәтләр өчен 6000 сум түләргә кирәк. Балалар бакчасына, күп балалы гаилә буларак, 50 процент ташлама белән 3000 түлибез. Әле бит бензины, башка вак-төяге дә бар… Кыскасы, чыгымнар җитәрлек, – ди Илсөяр апа.

Бүлмәдә уйнап йөргән балаларга карап: «Мондый шартларда ничек шулай күп бала табарга курыкмадыгыз соң?» – дип сорадым.

– Һәр бала үз ризыгы белән туа. Ходай бирсә, тагын табам әле. Дөрес, яшем 47дә, – ди ул.

Вәлиевләрнең торак мәсьәләсе буенча Совет районы хакимиятенә мөрәҗәгать иттек.

– Вәлиевләр кебек аерым категориягә караган, торакка мохтаҗ булган гаиләләр район буенча җитәрлек. Барысы да чират буенча көтә. Быелгы җәйдә Вәлиевләргә яңа фатиргә күченә алыр, дип уйлыйбыз. Алга таба аларга тагын бер фатир бирү дә күздә тотыла, – дип аңлаттылар безгә районның торак сәясәте бүлегендә.

РЕДАКЦИЯДӘН.

Әлеге мәсьәлә редакция хезмәткәрләре арасында да зур бәхәс уятты. Бер яктан, закон буенча бу гаиләгә ярдәм тиеш; икенче яктан, шактый ярдәм күрсәтелгән дә инде. Өченчедән, гаиләдә биш зур кеше бар, «бала» дигәннәре дә үзләре гаилә корып, акча эшләп, бала үстерерлек. Барысы да сау-сәламәт, эшлим дигән кешегә эш тә табарлык. Ничектер үз бурычыңны кеше өстенә йөкләргә тырышу кебек килеп чыга. Ә сез бу хакта нәрсә уйлыйсыз? Фикерләрегезне көтәбез.

Пособие артты

1 февральдән балалары булган гражданнарга түләнә торган пособиеләр суммасы индексацияләнде.

613,14 сум — **йөклелекнең иртә срогында медицина оешмаларына исәпкә баскан хатын-кызларга бер тапкыр бирелә торган пособие**

23120,66 сум — **бала тугач бер тапкыр бирелә торган пособие**

3065,69 сум — **беренче баланы караган өчен ай саен түләнә торган минималь пособие**

6131,37 сум — **икенче, аннан соң туган балалар өчен айлык пособиенең минималь күләме**

23120,66 сум — **баланы караган өчен хезмәт хакының 40 проценты күләмендә түләнә торган пособиенең максималь суммасы**

КҮРШЕЛӘРДӘ

Башкортстанның Борай районында үзенчәлекле дәвалану комплексы төзергә җыеналар. Анда болан мөгезе ярдәмендә дәвалаячаклар. Алтай якларында мондый ысул күптәннән кулланыла икән. Шуңа да республикага туристлар агымы да зур дип аңлата белгечләр. Башкортстан да туристларны җәлеп итү максатын күздә тота. Хәзер күрше республикада боланнар үстерү белән ныклап шөгыльләнә башлаганнар, ел азагына кадәр мараллар санын 2000 башка җиткерергә исәплиләр.

***

Чуашстанның Шыгырдан авылында яшәүче Фәрит Җюпов ишегалдына җил белән эшли торган электр станциясе ясаган. Бу аның балачак хыялы булган. Әлеге станцияне Фәрит әфәнде 12 ел төзегән, проектны тормышка ашыруга барлыгы 2 миллион сум акча тотылган. Аның каравы, хәзер электр өчен бер тиен дә түләми Җюповлар, дип хәбәр итә «Азатлык».

***

Мари Элда «Антибрак Марий Эл» дип исемләнгән иҗтимагый оешма эшли башлаган. Алар балык тоту, аучылык өлкәсендәге тәртип бозуларга каршы көрәш алып барачак. Оешмада браконьерлык проблемасына битараф булмаган аучылар, балыкчылар берләшкән. Тәртип бозулар турында халыктан хәбәрләр кабул итү өчен оешмада «кайнар элемтә» номерын булдырырга да уйлыйлар.

Ә сезгә күпме тиеш?

Бу темага еш язсак та, пенсия түләү буенча мөрәҗәгатьләр шактый килде. Укучыларыбызны кызыксындырган сорауларга Россия Пенсия фондының Татарстан бүлеге идарәчесе Эдуард ВАФИН аңлатма бирде.

Эльвира МОЗАФФАР

Пенсия реформасыннан соң күп тәртипләргә үзгәрешләр керде. Хәзер пенсиягә чыккан вакытта стаж һәм баллар зур роль уйный. 2017 елда пенсиягә чыгу өчен күпме стаж һәм балл кирәк?

Пенсия исәпләүдә хәзер чынлап та төп нигез булып стаж һәм хезмәт хакы санала. Әйтик, быел пенсиягә чыгучылар өчен кимендә 8 ел стаж, 11,4 балл кирәк. Шул рәвешле пенсиягә чыгарга хокук бирә торган стажның күләме 2015 елдан алып һәр елны бер елга артып бара. Нәтиҗәдә, 2024 елда пенсиягә чыгучылар өчен 15 ел стаж кирәк булачак. Шулай ук тиешле күләмдә балл җыю да мөһим. Ул эшләгән еллардан, хәрби хезмәттә булган еллар, декрет еллары, инвалид баланы яки 80 яшькә җиткән өлкәннәрне караган вакытлар өчен билгеләнгән баллардан туплана (тулырак инфографикадан карагыз).

Әгәр кешенең җитәрлек дәрәҗәдә стажы һәм баллы булмаса, ул пенсиягә чыга алмый дигән сүзме?

Ниндидер сәбәпләр аркасында стажы тулмаганнарга социаль пенсия каралган. Тик бу пенсия хатын-кызларга – 60, ә ир-атларга 65 яшьтән генә бирелә. 2016 елның 1 декабреннән аның күләме – 7898 сум. (2017 елның 1 апреленнән артачак дип ниятләнә.)

Пенсиягә чыгу өчен кая мөрәҗәгать итәргә, ничә ай алдан әзерләнергә? Пенсия билгеләр өчен нинди документлар кирәк?

Пенсия яше җитәргә 6-12 ай кала, кеше, теркәлү урыны буенча, пенсия бүлекчәсенә мөрәҗәгать итә ала. Эшләүче кешеләрнең кирәкле документларын гадәттә, эш урыны буенча кадрлар бүлеге Пенсия фондына юллый. 2013 елның 20 маеннан (№330) кабул ителгән Министрлар кабинеты нигезләмәсе белән, документларны электрон форматта җыю да гамәлдә.

Картлык буенча пенсиягә чыкканда кирәкле документлар исемлегенә паспорт, шәхси лицевой счетның иминият номеры (СНИЛС), хезмәт кенәгәсе керә. Шулай ук 2002 елның 1 гыйнварына кадәр теләсә кайсы 60 ай өчен рәттән хезмәт хакы турында белешмә сорарга мөмкиннәр. Фамилия, исем, отчество алышыну, гаиләдә эшли алмаучы, иждивениедә булган кешеләр турындагы мәгълүматлар да пенсия билгеләгәндә роль уйный.

Бер танышым беркайда да эшләми. Пенсиягә чыгарга аңа бик аз вакыт калып бара. Пенсия фондына документларымны тапшырмасам да, миңа ул акчалар түләнәчәк дип уйлый. Ул хаклымы?

Документларын кеше Пенсия фондына тапшырырга тиеш. Эшләмәүчеләр, пенсиягә чыгар алдыннан, теркәлү урыны буенча пенсия бүлекчәсенә пенсия билгеләүне сорап, гариза язарга тиеш. Гадәттә, фондның базасында тупланган документлар нигезендә, кешегә пенсия билгеләнә. Тора-бара кеше өстәмә документлар алып килеп, пенсиясен кире исәпләтергә ала. Тик әгәр булачак пенсионер турында берниндидә мәгълүмат юк икән, аңа пенсия билгеләп булмый. Яше җитеп, пенсиядә булып саналса да, фондка гариза тапшырылган очракта гына пенсия билгеләнә. Узган айлар өчен акча бирелми.

Еш кына үзләрен дәүләтнеке булмаган пенсия фондыннан дип таныштырган егетләр, кызлар өйләргә ишек шакый. Алар паспорт, СНИЛС сорыйлар. Ниндидер тикшерүләр уздырабыз, диләр. Документларга кул куярга, тупланма өлешне дәүләтнеке булмаган пенсия бүлекләренә күчерергә үгетлиләр. Аларга ышанырга буламы?

Кат-кат кисәтәбез: Пенсия фонды хезмәткәрләре өйдән өйгә йөрми. Ниндидер документка кул куйдырырга теләүчеләргә, үзләрен пенсия бүлегеннән килдем диючеләргә сак карарга кирәк. 1967 елгы һәм аннан соң туганнар пенсия капиталларын үзләре теләгәнчә формалаштыра ала. Тупланма өлештән баш тартырга уйласаң, эш бирүче түли торган барлык иминият взнослары да иминият пенсиясен формалаштыруга гына китәчәк. Тупланма өлешне калдырырга теләгәннәрнең иминият взнослары тупланма һәм иминият өлешләренә буленәчәк. Кеше менә шул иминият өлешен дәүләтнеке булмаган пенсия фондына күчерә ала. Бу эштә саклык сорала. Дәүләтнеке булмаган пенсия фондына күчү процессы да, ышанычлырак булсын өчен, дәүләт Пенсия фонды аша башкарыла. Шуны да истә тотарга кирәк: пенсиянең тупланма өлеше саклана торган дәүләтнеке булмаган пенсия фондларын биш елга бер тапкырдан да ешрак алыштыру кертемче өчен отышлы түгел, бу инвестиция керемен киметә.

2017 елда пенсия өлкәсендә нинди үзгәрешләр көтелә? Пенсия артачакмы?

Былтыр пенсияләрне чираттагы индексацияләүне бер тапкыр бирелә торган 5 мең сум түләү белән алыштырдылар. 2017 елда февраль индексациясе гадәти формада, 2016 ел өчен тупланган инфляция йомгаклары буенча, тулы күләмдә башкарыла. 1 февральдән иминият пенсияләре 5,4 процентка артты. 1 апрельдән социаль пенсияләрнең артуы көтелә. Ничә процентка икәнлеге төгәлрәк март аенда билгеле булачак. Февральдән федераль ташламага ия гражданнарга тиешле айлык түләүләр (ЕДВ) дә индексацияләнде. Татарстанда эшли башлаган электрон сервис нигезендә, социаль хезмәтләргә ия кешеләр моны Пенсия фонды сайтының шәхси кабинеты аркылы да эшли ала. Социаль җыелма сайлыймы, аны акчалата аламы, бу хакта 1 октябрьгә кадәр электрон формада гариза тапшыру мөмкинлеге тудырылды.

Эшләүче пенсионерларны нинди яңалыклар көтә? Пенсионер, эштән киткән очракта, индексацияләнгән пенсияне алырга хаклымы?

Эшләүче пенсионерлар өчен, традиция буенча, август аенда яңадан хисаплау үткәреләчәк. Февральдәге пенсияләр арту эшләүче пенсионерларга кагылмый. Дөрес, пенсионер, эштән киткән очракта, индексацияләнгән пенсияне алачак. Тик закон нигезендә, эштән китү турындагы приказ чыгып, өч ай узганнан соң гына. Әйтик, пенсионер быелның 1 гыйнварыннан эштән киткән, ди. Индексацияләнгән пенсияне ул бары (февраль, март, апрель) 1 майдан гына ала башлаячак.

Пенсия яшен арттыралар диләр, бу дөресме?

Әлегә бу хакта берниндидә документлар юк, законнар кабул ителмәде. Гадәттәгечә, картлык буенча пенсиягә ир-атлар – 60, хатын-кызлар 55 яшьтән чыга. Ә менә дәүләт хезмәткәрләре һәм муниципаль хезмәткәрләр 2017 елның 1 гыйнварыннан пенсиягә соңрак китәчәк. Аларның пенсия яше ел саен алты айга артып барачак. Нәтиҗәдә дәүләт структурасында хезмәт итүче ир-атларның пенсия яшен – 65, хатын-кызларныкын 63 яшькә кадәр озайту ниятләнә.

Бүген Татарстанда ничә пенсионер исәпләнә һәм картлык буенча бирелә торган уртача пенсия ничә сум?

Бүген республикада уртача иминият пенсиясе 12400 сумны тәшкил итә. Республикада барлыгы 1 миллион 128 мең пенсионер исәпләнә.

Яшь кешеләр бүген үк үзләренең булачак пенсияләрен исәпли алалармы?

Әйе, моның өчен Россия Пенсия фондының рәсми сайтында шәхси кабинетыңны булдырырга кирәк. Шулай ук дәүләт хезмәтләре порталы аша да шәхси кабинетка керү мөмкинлеге бар. Анда һәр кеше чама белән үзенең булачак пенсиясен исәпли ала.

Пенсияне ничек исәпләргә?

Яңа система нигезендә, картлык буенча пенсия, нигездә, өч өлештән туплана: фиксацияләнгән, ягъни бердәй түләү, тупланма өлеш һәм иминият пенсиясе. Фиксацияләнгән түләү бар кеше өчен дә бер үк. Ул ел саен индексацияләнә. 2017 елда аның күләме 4805,11 сум булды. Иминият пенсиясе исә кешенең пенсия баллары кушылмасына карап җыела. Бер балл 1 февральдән 78 сум 28 тиенне тәшкил итәчәк. Кыскасы, картлык буенча билгеләнә торган пенсия түбәндәге формула буенча билгеләнә:

Иминият пенсиясе = пенсия баллары X шәхси пенсия коэффициенты (78 сум 28 тиен) + фиксацияләнгән түләү (4805,11 сум)

Киләсе тема юл хәрәкәте иминлегенә багышланачак. Балаларны автомобильдә йөртү кагыйдәләре, аларны бозган өчен штрафлар күләме, автолюлка һәм автоколяскалар сайлау тәртибе турында сөйләшәчәкбез. Кызыксындырган сорауларыгызны редакциягә **(843) 562-50-03, 8(917) 851-69-62** телефоннары аша җиткерә аласыз.

САК ЙӨРЕГЕЗ

tatar-inform.ru

Узган атнада бер-бер артлы кайгылы хәбәрләр килеп торды. Пәнҗешәмбе көнне Казан–Малмыж юлының 31нче чакрымында, Бөреле тимер юл станциясе тирәсендә булган зур авариядә журналист Эльвира Ибраһимова (күпләр аны Мотавалова дип белә) һәлак булды. Аның белән якыннан таныш булганнар, ягымлы тавышын тыңлап, күңелләренә тынычлык алган радио тыңлаучылар айнып җитәргә, тын алырга да өлгермәде, икенче көнне үк тагын бер фаҗига турында хәбәр килеп ирешә. Минзәлә театры актрисалары Эльмира Әхмәтханова белән Эльмира Гәрәева М-7 трассасында һәлак булган...

Зөһрә САДЫЙКОВА

«БАЛАМ КАЙТУЫМНЫ КӨТЕП ТОРА»

Эльвира ханым «Болгар FM», «Биектау FM» радиоларында, башка матбугат чараларында эшләде. Соңгы көннәрә кадәр «Ярдәм» мәчете каршындагы тернәкләндерү үзәгендә хезмәт куйды. Никахлар, хәлал мәҗлесләр дә алып бара иде. Озак еллар безнең газетага тугры булган укучыларыбыз аны әле «Шәһри Казан» журналисты буларак та хәтерлидер.

– Без Эльвира белән кайчандыр «Шәһри Казан» газетасында бер бүлмәдә утырып эшләгән идек. Аның үлеме тетрәндерде. Эльвира киләчәккә матур хыяллар белән яшәде. Ул әдәбият, сәнгать кешеләренә тартылды. Үзе дә шигырьләр язды. Шәһәрдә яшәсә дә, туган авылы Таузардан (Балтач районы) аерылмады. Атна саен әнисенең хәлен белергә кайтып йөрде. Җәйләрен улы да авылда яшәде. «Нигә соңга калып юлга чыгасың?» – дигәч тә: «Аллага тапшырган инде, бала минем кайтуымны көтеп тора бит», – ди торган иде. Мин Эльвираны әчкерсез, кешеләргә ярдәмчел булганлыгы өчен хөрмәт иттем. Соңгы күрешүебездә ул үзенең эшен яратып эшләвен, машина йөртүен, Биектауда яшәвен сөйләгән иде. «Аның каравы гаилә бәхете булмады», –дигәненә каршы: «Булыр, син бит әле яшь», – дип кенә әйтә алдым. Аның күзләренә моңсулык иңгән иде... – дип истәлекләре белән уртаклашты хезмәттәшебез Люция Хәбибуллина.

Мәдәният, театр эшчәнлегенә кагылышлы темаларны яктыр-

тучы журналист буларак Люция Хәбибуллина, әлбәттә, Минзәлә татар дәүләт драма театры актрисаларын да бик яхшы белә иде. Алар белән берничә тапкыр әңгәмәләр дә эшләде. 21 ел буена әлеге театрда хезмәт куйган Татарстанның атказанган артисты **Эльмира Гәрәева** белән чираттагы очрашулары ике ай элек кенә Минзәлә театры коллективы Казанга гастрольләргә килгәч булган иде. Ул вакытта газетабызда зур гына әңгәмә дә басылды. Шундагы кайбер өзекләргә кабат тукталасы килә.

« **– Эльмира, син тудырган хатын-кыз образлары арасында авырулары да, үлеп киткәннәре дә бар. Тормышта аларның тискәре тәэсирен тоймыйсыңмы?**

– Чыннан да, мин бервакыт шул авыр язмышлы рольләрне уйнаганнан соң куркып авырый башладым. Бераз сәхнәдән читләшеп тордым, труппа мөдире вазифаларын башкардым. Кияүгә чыгып балалар үстерә башлагач, кабат сәхнәгә кайттым.

– Күптән хыялланган ролең уйналдымы әле? Ул нинди роль булыр икән?

– Юк әле, андый ролем уйналмады. Минем ни өчендер электән үк, кайберәүләр кебек, Галиябану, Мәйсәрәләрне уйныйсым килмәде. Урта буынга туры килә торган хатын-кыз язмышын гәүдәләндерергә тиеш ул образ. Әлбәттә инде, ахыры яхшы тәмамлансын иде аның.

– Син әле укуда, әле гастрольләрдә йөрисең. Ирең көнләшмиме?

– Юк, ул балаларны карарга ярдәм итә. Әни бик булыша. Гаиләдә аңлашылмаучанлык булганда, театрда эшләп булмый ул.

– Юлга чыкканда ырымнарга, юрауларга ышанасыңмы?

– Юк, мин андый нәрсәләргә ышана алмыйм.»

Эльмира Әхмәтханова да халык күңелендә якты йөзле, тыйнак, талантлы артист, тормышның барлык сынауларын сабырлык белән кабул итүче тырыш ханым булып истә калачак.

САН САЕН – КЕШЕ ЯЗМЫШЫ

Журналист Эльвира Ибраһимованың 13нче модель «Лада»сы да, Минзәлә актрисаларының машиналары да фура астына эләккән. Шушы берничә көн эчендә генә дә хәбәрләр тасмасында авыр йөк машиналары катнашындагы дүрт-биш юл һәлакәте (берсендә берничә фура бәрелеште) турында ишетергә туры килде. Очраклылыкмы, әллә соңгы вакытларда зур юлларда йөк машиналары катнашындагы юл һәлакәтләре чыннан да артканмы? Татарстан буенча Эчке эшләр министрлыгының ЮХИДИ идарәсеннән алынган мәгълүматларга караганда, гыйнварда республикада 296 юл һәлакәте теркәлгән, аларда 27 кешенең гомере өзелгән. 1-6 февраль аралыгында 61 авариядә алты кеше һәлак булган. Җаннарны тетрәндергән, күңелләрне пәрә-пәрә актарып ыргыткан фаҗигаләр, аһ-һай, күбәйде шул. Болары – коп-коры фактлар, ә бит һәр сан артында никадәр кеше язмышы – вакытсыз өзелгән яшь гомерләр, әти-әни назыннан мәхрүм калган ятимнәр, сөйгәннәрен ерак юллардан көтеп ала алмаган толлар, җан җимешләрен үзләреннән алда җир куенына салган аналар... Кызганыч, кайвакыт без бөтенебез дә ваемсызлык – һәр нәрсәгә битарафлык, салкын караш дигән

ЗУР ЮЛЛАРДА!

чирдән интегәбез! Күпвакыт үзебезгә, яки якыннарыбызга кагылгач кына, үрле-кырлы бәргәләнәбез. Ә бит көн саен ничәмә-ничә кешенең гомере юлларда өзелә.

Гыйнвар аеның рәсми статистика мәгълүматларына күз салсак, юл фаҗигаләренең якынча 8,4 процентында машина йөртүче гаепле дип табылган. 296 юл һәлакәтенең 25 очрагында авыр йөк машиналары катнашкан. Татарстан буенча Эчке эшләр министрлыгының ЮХИДИ идарәсенең матбугат чаралары белән эшли торган бүлегендә безгә: «Ләкин 25 очракта да фура йөртүчеләре гаепле дигән сүз түгел. Гадәттә, аларның гаепләре сирәк очракта гына исбатлана», – диделәр.

ФУРА ЙӨРТҮЧЕ РАМИЛ: «ТРАССА – БЕЗНЕҢ ЭШ УРЫНЫБЫЗ»

Бу темага язарга алынгач, фура йөртүченең үзенең дә фикерен тыңлау файдалы һәм мәгълүматлы булыр дип, без Рамил Шаһидуллин белән сөйләштек. 35 яшьлек ир-атның ерак араларга товар ташуда эш тәҗрибәсе 13 елга тулган.

– Эш тәҗрибәмдә бөтен Россияне, Европаны, Әзәрбайҗанны йөреп чыктым. Хәзерге вакытта «Деловые линии» оешмасында эшлим. Без хәзер «тахограф өчен йөртүче юл картасы» белән эшлибез. Бу эш һәм ял режимы саклансын өчен эшләнелә. Анда безнең никадәр юл узганлыгыбыз, күпме ял иткәнлегебез турында мәгълүмат туплана. Яңа закон кагыйдәләре буенча, минем эш көнем тугыз сәгатьтән артмаска тиеш. Бу аварияләр, юлда төрле күңелсез хәлләр килеп чыкмасын өчен шулай эшләнелә. Әлеге вакытта Түбән Новгород – Мәскәү – Чиләбе – Казан – Уфа маршруты буенча эшлим. Бер пункт белән икенче пункт арасын узарга тугыз сәгатьтән артык вакыт таләп ителсә, ике йөртүче бер-берсен алыштырып бара. Ял итү режимына килгәндә, без тәүлегенә, ким дигәндә, 11 сәгать ял итәргә тиеш. Мин, мәсәлән, дүрт сәгатьлек юлдан соң 45 минут ял итеп алам, аннан соң тагын дүртбиш сәгатьлек юл узам. Әгәр бөтен оешмалар да безнең кебек закон буенча эшләсәләр, акрынлап барысы да җайга салыныр иде.

– Закон тарафыннан мондый кагыйдәләр кертелү яхшы икән. Алайса айлар буена юлда булырга туры килгәч, тиешенчә ял итәсезме икән, дип уйлыйбыз бит сезне.

– Бу үзгәрешләр, яхшыга, әлбәттә. Чөнки элек хезмәт хакы үтелгән чакрым өчен түләнә иде, ягъни никадәр күбрәк юл узасың, акчаны да шулай аласың. Шуңа күрә кешеләр көне-төне эшләделәр дә. Ә хәзер билгеле бер хезмәт хакы бара. Бу эш Европада күптән җайга салынган инде, бездә генә әле тиешле дәрәҗәдә эшләп китә алмый, дип саныйм. Законны утәмәүчеләр дә җитәрлек. Шуның аркасында менә шундый фаҗигаләр килеп чыга да инде. Тугыз сәгать эшләп, яхшы хезмәт хакы түләсәләр, бөтен кеше безнең кебек эшләр иде. Мин, мәсәлән, атнага ике тапкыр ерак юлга барып кайтып кулга 55 мең сум акча алам.

– Шәхсән үзегезнең җитди юл һәлакәтенә эләккәнегез булдымы?

– Юк, Аллага шөкер. Бер тапкыр бозлавык вакытында Омскида юл читенә төштем.

– Соңгы көннәрдә фуралар катнашындагы юл һәлакәтләре турында күп ишетергә туры килде. Моңа карата да сезнең фикерне ишетәсе килә иде.

– 13 ел ерак юлда йөргән кеше буларак, төрлесен күрергә туры килде анысы. Шуны әйтәсе килә: юл һәлакәтләре машиналар югары тизлек белән йөргәнлектән генә килеп чыкмый, күп очракта йөртү культурасы җитми. Һәр авариянең үз тарихы, машина эчендә утырган кешеләрнең үз язмышы.

– Берсе артыннан берсе тезелешеп килгән авыр йөк машиналары да җиңел автомобильләр хәрәкәтенә комачаулык ясый.

– Безнең барыбызның да кабиналарында рация тора. Бер-беребез белән аралашыр өчен, үзебезнең эш каналыбыз бар. Аның ярдәмендә, ким дигәндә, ике чакрым ераклыктагы кеше белән элемтәгә чыгарга мөмкин. Юл йөрү кагыйдәләрен күпчелек очракта җиңел машиналар боза. Трасса – безнең эш урыныбыз, шуңа күрә без, авыр йөк машиналарында йөрүчеләр, юлда тәртип урнаштырырга тырышабыз. Бәлки, бераз сәеррәк яңгырар, әмма без алар аркасында бәла-казалар азрак килеп чыксын өчен тырышабыз. Аннан соң, тезелешеп баруның сәбәбе – ул-бу була калса, бер-беребезгә ярдәмгә килергә әзер булып тору.

– Юлда ял итәр өчен шартлар бармы?

– Әйе, туктап, ашап-эчеп алырга да, юынырга да, массаж ясатырга да мөмкин. Соңгы елларда намаз уку, гыйбадәт кылу урыннары да шактый ачылды. Бу миңа, диндәге кешегә, аеруча мөһим.

– Рамил, гаиләгез бармы?

– Хатыным, балабыз бар.

– Сез эшкә чыгып киткәндә, тормыш иптәшегез ут йотып торадыр төсле тоела.

– (*Көлә.*) Сез генә шулай уйлыйсыз, ияләште инде ул. Эшемне ул да, мин дә гадәти эш дип кабул итәбез.

«ЙӨРТҮЧЕЛӘР ҖИТДИ ТИКШЕРЕНҮ УЗА»

Трассаларда ерак араларга пассажирлар йөртүче зур автобуслар да күп очрый. Татарстанның иң эре шәхси оешмаларының берсе булып торган «Апельсин» пассажир агентлыгы 2007 елдан бирле эшли. Азнакай – Казан – Азнакай, Азнакай – Чаллы, Азнакай – Башкортстан – Казан маршрутлары буенча хәрәкәт итүче агентлыкның 60лап автобусы бар. Җитәкчесе Рамил Шәйхелисламов сүзләренә караганда, автобус шоферларын эшкә алган вакытта иң беренче чиратта кешенең эш тәҗрибәсенә карыйлар. Дөрес, эшкә тәҗрибәсе булмаганнарны да алырга мөмкиннәр, әмма аларга таләпләр дә катгыйрак куела. Андыйларны автобус руле артына утыртканчы, төрле категориядәге машиналарда йөртеп сыныйлар. Шуннан соң икенче таләп – медицина белешмәсе булу.

– Әмма медицина белешмәсендәге мәгълүматка гына ышанып бетмибез әле, үзебез дә тикшерәбез. Характерына игътибар зур. Психик тайпылышлары юкмы, критик ситуациядә үзен кулда тота алачакмы – шуларны карыйбыз. Кайвакыт карап торышка тыныч кына күренгән кеше дә билгеле бер очракта «бәйдән ычкынырга» мөмкин. Андыйлар да очрый. Шушы ике этапны үткәннәргә генә стажировка, инструктаж уздырабыз.

Бер автобус өчен ике йөртүче җаваплы икән. Азнакай – Казан арасы – биш сәгатьлек юл. Шофер, ярты юлда туктап, 25 минут тирәсе ял итеп ала. Шуннан соң Казанга килеп җиткәч, бераз ял итә дә, башкаладан районга кайтучы пассажирларны алып, кире кайтыр юлга кузгала. Гадәттә, алдагы көнне юлга икенче йөртүче чыга, әмма кайвакыт ике көндә дә шул ук бер шофер эшләргә мөмкин икән.

Җитәкче әйткәнчә, юлга кузгалыр алдыннан, йөртүчеләр һәрвакыт медицина тикшеренүе уза. Шуннан соң гына юлама алып, автобусын механикка күрсәтә. Медицина тикшеренүен уза алмаганнар да очрый.

– Берсендә шофер Казанга барырга әзерләнә. Карыйбыз, йөзе кып-кызыл моның. Хәле дә юк, ә үзе: «Барам!» – дип тора. Кан басымын тикшереп карагач, аның югары булуы ачыкланды. Хәтта «ашыгыч ярдәм» машинасы чакыртып, хастаханәгә озатырга туры килде, – ди Рамил әфәнде.

Юл һәлакәтләренә кагылышлы сорауларыбызга да җавап ишетәсе килде.

– Шоферларга без трассада тизлекләрен сәгатенә 100 чакрымга кадәр арттырырга рөхсәт итәбез. Аларның тизлекләрен датчик аша тикшереп тора торган махсус белгечебез бар. Ә аварияләр мәсьәләсенә килгәндә, алар булып тора. Без дә, башкалар да гаепле булган очраклар бар. Юл һәлакәтләренең беренчесе – кеше факторы. Күп нәрсә йөртүчедән, аерым алганда, аның холык-фигыленнән, эш тәҗрибәсеннән тора. Аннан соң гына сәбәпне машинадан эзләргә кирәк, – дип саный ул.

Тизлек буенча иң катгый чикләүләр нәкъ менә пассажирлар йөртүче зур автомобильләргә куела. Закон таләпләре буенча, аларның максималь тизлекләре – сәгатенә 60 чакрым. Ә менә В категориясендәге авыр йөк машиналарының хәрәкәте зур юлларда сәгатенә – 90 чакрымнан, ә торак пунктларында сәгатенә 60 чакрымнан артмаска тиеш. С һәм CE категориясенә барлык төр авыр йөк автомобильләре, шул исәптән фуралар керә. Автомагистральләрдә алар тизлекләрен сәгатенә – 90, шәһәр яны юлларында сәгатенә – 70, ә торак пунктларында сәгатенә 60 чакрымнан арттырырга тиеш түгел.

Әлеге телефон номерларын җыярга беребезгә дә насыйп булмасын, әлбәттә, әмма трассада юл һәлакәтенә очраган вакытта – 5-333-888, ә Казан шәһәрендә 5-333-900, кәрәзле телефоннан 112 номерларына шалтыратып хәбәр итәргә кирәк. Шулай ук юл йөрү кагыйдәләре бозылган очракка тап булсагыз, «халык контроле» мессенджерына язып җибәрергә мөмкин.

Медицина ярдәме күрсәтү

Юлларда медицина ярдәме күрсәтү турында Татарстанның сәламәтлек саклау министры **Адел ВАФИН** сөйләде:

– 2009 елда «Сәламәтлек» илкүләм проектын гамәлгә ашыру кысаларында, республикада юл һәлакәтләрендә зыян күрүчеләргә ярдәм күрсәтүне яхшырту буенча чаралар тормышка ашырылды. Шушы проект нигезендә беренчеөченче дәрәҗәдәге травматология үзәкләре эшли башлады. Һәлакәт булган урыннарга С классындагы реамобильләрдә анестезиолог-реаматологлар чыга. Кирәкле ярдәм җәрәхәт алганнан соңгы якын арада ук күрсәтелә. Нәтиҗәдә, юлларда һәлак булучылар саны ел саен кими, әмма монда нәрсәгә басым ясарга: яхшы юллар төзелү белән бергә, машина тизлекләрен арттырыр өчен шартлар да туа. Күпчелек кеше «ашыгыч ярдәм» бригадалары килеп җиткәнче үк үлә. М7 трассасы буенча узган ел күрсәткечләре 86 проценттан 93 процентка кадәр үсте. Шуңа күрә машина йөртүчеләр үзләре беренче медицина ярдәме күрсәтә белергә тиеш. Бу бик мөһим, чөнки никадәр гомерне саклап калып булыр иде.

Быел Татарстан санитар авиацияне тормышка ашыру программасына кертелде. Президент ярдәмендә, медицина модуле белән беренче вертолет сатып алынды. Тиздән ул эшли башлаячак. Авария травматология үзәкләренә ераграк булган очракта, әлеге вертолетлар авыруны һәлакәт булган урыннан алып китәчәк.

Бөтен кешедә дә машина булу яхшы, әлбәттә, ләкин юллардагы тәртипсезлек нәтиҗәсендә өзелгән меңнәрчә гомерләр бик кызганыч. Медицина алга барганда, заманча шартларда бу алай булырга тиеш түгел. Шуңа күрә йөртүчеләргә карата да таләпләрне катгыйландырырга кирәк, – диде Адел Вафин.

Министр сүзләре белән килешми мөмкин түгел. Кемдер руль артында, кемдер җәяүле, кайсыбыздыр пассажир булып чыга юлга. Юлларда өзелгән гомерләрне искә төшереп, бер-беребезгә игътибарлы булып, җаваплылык турында да онытмасак, ашыкмасак иде. Нәкъ җырдагыча, хәерле юл теле һәйкәлләр...

Айдар Галимов авыл җирле үзидарә җитәкчесе белән.

Галимовларның җырлы гаиләсе.

Кәркәле таулары биек, Биек булса да меник

Таныш җырмы? Кайда соң ул Кәркәле һәм аның таулары шулкадәр биек микәнни?!

Башкортстанның Миякә районында Олы Кәркәле авылы бар. Айдар Галимовның туган җире ул. Кәркәлегә беренче килүем түгел. Ел да уздырыла торган «Айдар Галимов кубогына футбол чемпионаты»на берничә тапкыр бардым.

Матур һәм төзек авыл. 202 хуҗалыкта барлыгы 540 кеше яши. Балалар бакчасына 25 бала йөри, тугызъеллык мәктәптә 61 бала укый. Азык-төлек, көндәлек кирәк-яраклар сатыла торган кибетләре бар. Авылның матур җирләренең берсе – «Ракай» чишмәсе. Ул матур коймa белән әйләндереп алынган, ял итү өчен өстәл белән урындыклар да куелган.

Олы Кәркәле авыл советына Камышлы, Яшьләр, Җидеган, Бәләкәй Кәркәле, Олы Кәркәле – татар һәм Уязыбаш, Верхоценко, Дубровка, Смородиновка – чуваш авыллары керә. Җидегәндә яшиме, Яшьләрдәме, Дубровкадамы – «Мин – Кәркәледән» дип сөйләшә алар. Авыллар бер-берсенә бик якын урнашкан.

Җырчының туган йорты.

Олы Кәркәленең Беренче май урамында Галимовлар гаиләсе яши. Бибинур апа Олы Кәркәлегә 1961 елда татар теле укытучысы булып эшкә килә. Ул заманда авыл клублары гөрләп торган, яшьләр көн дә кичәләр оештырган. Бибинур армиядән яңа гына кайткан, гармунда өздереп уйнаган шушы авыл егете Минеганигә гашыйк була. Яшьләр 1963 елда өйләнешәләр. Күрше авыл – Яңа Ишледә туып-үскән Бибинур апа 55 ел инде Олы Кәркәледә яши.

– Кәркәлене бик яраттым. Мин эшкә килгәндә, мәктәбендә 400 бала укый иде. Рәхәтләнеп, бөтен күңелемне биреп эшләдем. Җидееллык мәктәп тугызъеллыкка әйләнде, аннары – унбер. Укучылар саны кимеп, бүген кабат тугызъеллыкка калдырылды, – ди Бибинур апа. – Заманында колхозыбыз да бик матур һәм көчле иде. Бер вакыт хуҗалыкларны «ООО»га әйләндерделәр бит. Шул үзгәрешләрдән соң колхоз юкка чыгып бетә язгач, аны Гаделшин Марат исемле егет үз кулына алып, әкренләп терәкләндереп килә. Фермада маллары бар. Анда авыл халкы эшли. Басулар буш түгел, анда иген үсә, Аллага шөкер.

Җиңүнең 70 еллыгын билгеләгәндә, Олы Кәркәледә сугышта һәлак булганнар истәлегенә обелиск ачылды. Олы Кәркәле авыл советыннан сугышка 485 кеше китеп, шуларның 230ы гына туган якларына әйләнеп кайта. Туган ил азатлыгы өчен гомерен биргән һәр авылдашның исеме ташка уелып язылган. Обелиск каршында пыяла тартма эчендә корыч каска да бар. Аны һәйкәл ачылышына Курск дугасы (Липецк өлкәсе) сугышы урынынннан махсус алып кайтканнар. Тарихчылар касканы 112нче Башкорт атлы дивизиясе яугирләренеке булган, ди.

Айдар Галимов, фронтовик оныгы буларак, туган авылында һәйкәл ачуны үзенә күптән бурыч итеп куйган булган. Әлеге изге эшне ул авыл җитәкчеләре белән берлектә, дуслары ярдәме белән башкарып чыга. Тик Бибинур апа, артык тыйнак булгангамы, улын мактарга, «Айдар эшләде», – дип әйтергә кыенсына.

– Бәлки кемгәдер бу һәйкәлнең мөһимлеге аңлашылып та бетмидер, әмма ул кирәк. Авыл халкына гына түгел, үсеп килүче яшь балаларда патриотик рухны тәрбияләүгә, батыр яугирләр истәлегенә, тарих өчен кирәк. Һәйкәл бик зур, шәһәрләрдәгечә! Төн буе ул матур итеп яктыртыла, балкып тора, – ди Бибинур апа. – Берничә ел элек авылда чишмә дә яңартылды. Мин авылга килгәндә, ул тал арасындагы ташландык чишмә иде. Янәсе, авылга тәүдә Ракай исемле бабай килеп урнашкан булган, чишмә дә аның исемен йөртә – «Ракай» чишмәсе. Шөкер, хәзер чишмә авыл яме булып тора, авылдашлар аны саклап карый. Бүген һәр йортка су кергән, чишмәгә йөреш юк. Кирәк чакта гына файдаланыла. Туй кебек бәйрәмнәр булганда чишмәгә бару – матур йола.

Авыл халкы Айдар Галимов белән горурлана һәм аны һәркайсы ярата. Олы Кәркәле белән бәйле бер чара да ансыз үтми. Соңгы арада сольный концертларын куйганы юк, Миякә ягысә Стәрлебаш район үзәкләрендә булса, халык шунда бара. Шулай да, халык аның тамашаларын еш күреп тора: чөнки чишмә, мәчет, һәйкәл ачылу тантаналары һәрвакыт «Айдар» студиясе белән берлектә әзерләнә.

– Авыл халкының Айдарга булган мөнәсәбәтен әйтә алмыйм. Әмма улым бик кешелекле, тәүфыйклы, – ди әнисе. – Авылда, руль артында барганда, урамда кем генә очрамасын, ул аның янына төшеп исәнләшә, бала-чагаларга машинасын «пипелдәтеп» кул болгый. Беркайчан да зур тизлек белән аларны үтеп китми. Һәркайсын таный, кем баласы икәнен, исемен дә белә. Айдар аларга карата игътибарлы булгач, авыл халкы аңа карата начар мөнәсәбәттә димәс идем. «Дустан дошман күп», – диләрме әле, заманы бүген шундый. Тәнкыйтьләүчеләр, эч пошкан кешеләр дә бардыр, аларсыз да булмый.

Олы Кәркәле җирле үзидарә җитәкчесе Азат Хәмидуллин да Айдар Галимовны мактап телгә алды. Җырчы туган авылына кайткан саен, сельсовет янына кереп, авыл хәлләрен белешеп чыга. Дәүләт Җыелышы-Корылтай депутаты буларак та, авылны хәстәрләп кенә тора.

– Айдар Галимовны мисалга куеп, яшьләрне дә тәрбиялим. «Менә, карагыз, Айдар абыегыз әти-әнисенә карата нинди игътибарлы. Нәрсә генә булмасын – шундук кайтып төшә. Бераз авырып торса да, хастаханәгә алып бара, дәвалый. Шуңа да аның эшләре гел уңа», – дип әйтәм, – ди үзидарә рәисе. – Әти-әнисенә генә түгел, янындагы бар кешегә дә игътибарлы ул. Улым Әстерханда армиядә хезмәт итте. Айдар бервакыт миңа шалтырата: «Синең улың Әстерхандамы әле ул? Хәйрия концертында чыгыш ясарга шул якларга китеп барам. Улыңны хәрби частьтан алып чыгып, шәһәр күрсәтергә иде», – ди. Улым башта кыенсынды, «Юк, кирәкмәс», – диде. Әмма Айдар барыбер янына барган, алып чыгып концерт күрсәткән, шәһәрдә йөрткән. Аның белән Татарстан егетләре дә хезмәт иткән, алар башта ышанмаганнар, шаккатканнар. Айдар гына түгел, авылыбыздан чыккан барлык кешеләр дә ярдәмчелләр. Нинди генә эшкә тотынма, ярдәм кирәк икән, кем күпме булдыра ала – булышырга әзер торалар. Әйткәнемчә, Айдар Хәлим дә безнең авылныкы, безнең горурлыгыбыз!

Кәркәле ул бер матур гөл кебек. Әйе, матур җирдә үсеп утыручы. Ә иң мөһиме – ул гөлгә су сибеп торучылар бар. Димәк, авылның киләчәге өметле.

Азалия ИСМӘГЫЙЛЕВА.

АШ БУЛСЫН

Печеньедан торт

Печенье («К чаю») – 500-600 гр
Сөт – 200 мл
Эремчек – 500 гр
Сыер мае – 100 гр
Шикәр комы – 150 гр
Каймак – 50 гр
Порошок хәлендәге какао
Банан – 2 данә

Эремчек, йомшартылган сыер мае, шикәр комы, каймактан крем ясыйбыз. Һәр печеньены сөткә манып, аның өстенә крем сылыйбыз һәм түгәрәкләп туралган банан куябыз. Аның өстенә кабат печенье, крем, банан өябез. Иң өскә печенье куеп, какао сибәбез. Әстерхан чикләвеге белән бизәргә дә була.

Татлы борыч: гладиатор, Винни-Пух...

БАКЧАЧЫГА

Татлы борычтан югары уңыш аласыгыз килсә, аның түбәндәге сортларын алырга киңәш итәбез. Консервлау өчен Купец, Ермак, Виктория дигән сортлар яхшы.

Ермак дигәне тиз өлгерә, авырлыгы 250 граммга кадәр җитә. Квадрат метрга 12-15 килограммга кадәр уңыш бирә ала. Виктория конус рәвешендә, авырлыгы – 110 грамм, квадрат метрга 9-10 килограмм уңыш бирә. Салатларга кушарга, бакчадан өзеп кергә үк кулланырга дисәгез, Калифорнийское чудо, Гладиатор, Винни-Пух, Подарок Молдовы кебек эре, калын тышлы сортларга өстенлек бирегез. Гладиатор Голландия сорты, авырлыгы 380-400 граммга кадәр җитә. Калифорнийское чудо – уртача өлгерешле, утыртып 100-130 көн үткәннән соң гына уңыш бирә башлый.

ОСТА КУЛЛАР

Җептән шар чорныйбыз



1 2 3 4

ФАЙДАЛЫ

Сәламәтлек өчен – бәрәңге согы

- *Бәрәңге согында иммунитетны яхшырта торган С витамины бар.*
- *Икегә аерылган юка чәчләрне шулай ук бәрәңге согы белән дәвалыйлар. Аны чәч төбенә сылап 20 минут тотыгыз да юып төшерегез.*
- *Коры бит тиресен мамыкка манылган бәрәңге согы белән дымландырыгыз.*
- *Бәрәңге согы йөрәк өчен дә файдалы, ул холестерин күләмен киметә.*
- *Гастрит вакытында бәрәңге согын ун көн эчеп, ун көн тәнәфес ясарга кирәк. Иртән ашарга ярты сәгать кала, аны бер стакан эчәргә кирәк.*
- *Бәрәңге согы бавырны һәм үт куыгын агулы матдәләрдән чистарта.*
- *Аны еш эчкәндә, ашказаны-эчәклек тракты эшчәнлеге дә яхшыра.*

СӘЛАМӘТЛЕК

Озын гомер телим

Окинава утравында яшәүче ир-атларның уртача яше – 88, хатын-кызларныкы – 92. Аларның озын гомерле булу сере куркумада. Аңардан ясалган эчемлек яман шеш барлыкка килүне кисәтә, инфаркт, инсультны булдырмый калырга булыша. Әлеге эчемлекне әзерләү өчен бер стакан җылы сөткә 1/4 бал кашыгы куркума салабыз. Өстен каплап, биш минут тонәтәбез дә 1 чәй кашыгы бал салып эчәбез.

Куркума ашкайнатуны, матдәләр алмашын яхшырта, канны чистарта, холестеринны киметә.

ТӘМЛЕ

БАЛЫК пешерү серләре

Балык тәмле булып пешсен дисәң, кайбер серләрне белергә кирәк:

Диңгез балыгын кыздырырга 20 минут кала аның өстенә лимон согы сыгыгыз.

Океанда тотылган балыкны кыяр тозлыгында пешерегез.

Балык майлы булган саен тәмлерәк пешә. Майлылык буенча аларны өч төргә бүләләр.

Бик майлылар: мәрсин (осетр), сөләйман (лосось) балыгының кайбер төрләре, сельдь, минога, еланбалык (угорь), хамса, скумбрия.

Уртача майлылыктагылар: карп, сөләйман балыгының кайбер төрләре, камбала, җәен балык (сом).

Майсыз балыклар: тәрәч (треска), алабуга (окунь), чуртан (щука), керкә (форель).

Кыздыру өчен иң яхшы балыклар: карп, сазан, корбан балык (лещ), диңгез чабагы (корюшка), навага, кәрәкә (карась).

Балыкка тозны алдан ук сибеп куймагыз.

Төче сулыкларда яши торган балыкны башы белән пешерү яхшырак. Уха пешерү өчен дә яхшы ул балыклар.

Балыкны кыздырыр алдыннан 15 минут сөттә тотсагыз, ул сусылрак була.

МӘЛЕНӘ – ӘМӘЛЕ

Кер үтүкли торган тактага фольга куйсаң, үтүкләү тизрәк тә, җиңелрәк тә булачак. Тактаның чехолын салдырып, аның өстенә гади фольганы җәябез. Өстеннән кабат чехолны кидерәбез. Фольга җылылыкны кайтара, шуңа да киемдәге сырлар тиз үтүкләнә.

ХУҖАБИКӘГӘ

Чи күкәй тиз бозыла, шуңа да аны суыткычның туңдыру камерасында саклау хәерлерәк. Күкәйне контейнерга да, боз катыра торган махсус савытларга да тутырып куеп була.



БЕЛӘСЕЗМЕ?!

Торт өчен әзер коржлар

Торт өчен коржны ярты сәгатьтә пешереп була. Тугыз-ун данә корж өчен 200 грамм каймак, бер чәй кашыгы сода, 200 грамм шикәр комы, 3 стакан он кирәк була. Каймакка сода салып яхшылап болгатабыз, аның өстендә күбекләр пәйда булгач, шикәр комы салабыз. Бер минут болгаткач, аз-азлап он өстибез. Камырны тугыз-ун өлешкә бүлеп, һәрберсен уклау белән җәябез. Барысы да бертигез булсын өчен, җәелгән камыр өстенә уртача зурлыктагы тәлинкә куеп, әйләнәсен кисеп алабыз. Һәрберсен коры таба өстендә пешерәбез.

Резедә Хәйруллинадан үрдәк бәлеше

1 2 3 4 5 6

Камыр өчен 1 стакан җылы суга 1 чәй кашыгы тоз, 2 аш кашыгы майонез, 3-4 аш кашыгы үсемлек мае кирәк. Камырны басканнан соң 20 минут тотабыз. Эчлек өчен үрдәк итен, үрдәкнең эчәк-бавырларын ваклап туралган суган, бәрәңге тоз һәм борыч салып болгатабыз. Камырны җәеп, майланган табага салабыз. Эчлекне тутырабыз. Бәлешне ябып, камырны бөгәбез. Кыздырылган мичкә 1,5-2 сәгатькә куябыз.

Дилбәр ГАРИФУЛЛИНА әзерләде.

«Авылга кайтканыма үкенмим»

Балачак хыялына тугры калганнарны, үҗәтләрне ихтирам итәм. Кызганыч, андыйлар гына сирәк очрый. Күпләр: «Әй, хыял хыял инде ул. Яшәргә кирәк!» – дип көндәлек агымга ияреп, уңайлы, тыныч тормыш эзли, икенчеләр әз генә авырлык күрсә дә, кире чигенә. Ләкин бар, бар әле алар – хыялларына тугры калучылар да, үҗәтләр дә. Шундыйларның берсен Балтач районының Мельничная авылында таптым.

Зөлфия Хәлиуллина фотосы

Руслан Нәҗипов – авылда үскән егет. Балтач ягы авылларындагы тырышлык – канында. Ләкин замана шаукымы йогынтысында Руслан да Казанга китеп эшкә урнаша. Казан – кешене үз кысаларына кертә торган шәһәр, монда яшәгәч, башкаларча булырга кирәк. Руслан да моннан котыла алмый – яхшы эш, фатир, машина дигәндәй… Барысын да булдыра ул. Ләкин балачак хыялы, күңеле сораган шөгыль белән яшәү теләге тынгылык бирми.

Русланның кечкенәдән яраткан шөгыле – җирдә ни дә булса үстерү. Хәер, хыял түгел, эшләгән инде ул бу эшне.

– Мәктәптә укыганда ук бакчада нәрсә булса да үстерү теләгеннән арына алмадым. Әни белән бакча өчен ачуланышып бетә идек. Аннары компромисска килдек – бакчаны урталай бүлдек тә шулай утырта башладык. Яртысын әни утырта һәм карый, яртысын — мин. Помидор, кыяр, суган, борыч үстердем. Дөресен генә әйткәндә, минем як яхшырак уңыш бирә иде, – дип сөйли Руслан. – Җир кешесе мин. Шәһәрдә эшем яхшы иде, тик Казанда яшәүне гел вакытлыча хәл дип кабул итте күңелем. Тормышымда бераз үзгәрешләр булгач, тоттым да авылга кайтып киттем…

Әлбәттә, җиңел генә сөйләсә дә, төптән уйланылган карары була бу Русланның. Кайткач, күршедәге Мельничная авылында ташландык бер бина таба, Авыл хуҗалыгы министрлыгыннан грант алуга ирешә һәм әлегә безнең якта күренмәгән ысул – гидропоника ысулы белән яшел суган үстерергә тотына.

– Күп өйрәндем, укыдым бу хакта, – ди Руслан Нәҗипов. – Гидропоника ысулы ул – суганны туфраксыз, суда гына үстерү ысулы. Туфракта гади теплицада яшел суган 28 көндә өлгерсә, бу ысул белән ул 15 көндә үсеп җитә. Татарстанда бу ысул белән эшләүче юк, бары тик «Майский» совхозында гына бер стеллаж бар бугай. Ә миндә хәзер, үзегез күргәнчә, стеллажлар катлап эшләнгән. Урынга экономия. Бинаны җылытырга кирәк бит, нигә мин ул мәйданны әрәм итәргә тиеш ди?

Бинада әле әзрәк урын бар. Якын арада анда да стеллажлар урнаштырылачак.

Русланнан «Иң авыры нәрсә булды?» – дип сорыйм.

– Әти-әнинең аңламавы, – ди. – «Син нишләп кайттың авылга?» – дип алар аңламады. Ә болай, районнан ниндидер ярдәм булды дип әйтә алмыйм. Күп эшмәкәрләр әйтмешли, комачауламасалар – шул ярдәм инде.

Руслан лизинг ысулы белән эшне автоматлаштыру җайланмасы да сатып ала. Үзе әйтмешли, почмакта бер компьютер тора, су бирүне, температураны ул көйли.

Без килгәндә, Русланның уң кулы, авылдашы, сыйныфташы Айдар Әскәров әзер суганнарны үлчәп, кисеп, төргәкләргә урнаштыра иде.

Күпме суган җитештерүләре турында Руслан әйтмәде. «Файдасы бармы соң?» – дигәнгә: «Булмаса, һаман шуның белән шөгыльләнер идеммени?» – дигән сорау белән җавап кайтарды.

Җитештерү бер нәрсә, җитештергән нәрсәне сатарга да кирәк бит әле. Монысы да җайга салынган. Әлбәттә, Руслан үзе йөреп тапкан күпләп сатып алучылары.

100 квадрат метрлы, берничә кат стеллажлы теплицасы конвейер кебек эшли. Җыелган суган урынына көне белән икенче орлык урнаштырыла. Җитештерү көз кергәннән алып майның икенче яртысына кадәр бара. Хәер, җәйләрен дә җирдән аерылмыйлар. Басуда җирләре бар, анда шөгыльләнәләр. Киләчәктә башка төрле яшелчәләр дә үстерергә уйлыйлар…

– Авылда яраткан эшең белән шөгыльләнү шундый рәхәт. Ун елда, әлбәттә, кала тормышына өйрәнеп беткән булганмындыр инде. Тик бүген үземне авылсыз күз алдына да китерә алмыйм. Уйлавымча, хәзер яшьләр әкрен генә авылга кайта, ни белән булса да шөгыльләнә башлаячак. Башкача була алмый, чөнки заман, яшәеш шуны таләп итә.

Илфак ШИҺАПОВ.

Равил Сабыр:

«Борынны каната торган пьеса, диләр…»

Әлмәт татар дәүләт драма театры 19 февральдә «Сигезле бию» мелодрамасы белән Камал театрында гастрольләрен башлап җибәрә. Шул уңайдан «ШК» хәбәрчесе пьесаның авторы Равил Сабыр белән элемтәгә керде.

– Равил әфәнде, Казан тамашачысына беренче мәртәбә «Сигезле бию» әсәрегез тәкъдим ителә…

– Беренче генә түгел инде. 2011 елда Тинчурин театрында Чаллы труппасы гастрольләре узган иде, шул чакта минем өч әсәрем – «Абага алмасы ачы була», «Хәят» һәм Фаил Ибраһимов куйган «Сигезле бию»не уйнаганнар иде.

– Димәк, Әлмәттә бу пьесаның икенче куелышы?

– Юк, өченче. Әтнә театрында Рамил Фазлыев бу пьеса буенча «Күбәләкләр утка оча» исемле спектакль чыгарды.

– Өч куелыш — бүгенге пьесаларга сирәк эләгә торган бәхет, режиссерларны бу әсәрдә шулкадәр нәрсә кызыксындыра сезнеңчә?

– Режиссерлардан сорарга кирәк инде… Минемчә, монда эшнең прагматик ягы да бар. Сер түгел, безнең театрларда артисткалар, бигрәк тә урта яшьләрдәге ханымнар шактый, барысына да алар теләгән кадәр роль җитми. Ә бу пьесада шундук сигез артисткага роль әзер. Тик шул ягы да бар, театрлар пьесаларга нинди генә зур кытлык кичермәсен, режиссерга пьеса ошамаса, аның күңелендәге ниндидер нечкә кылларны тибрәндермәсә, ул беркайчан да эшкә алынмый.

– Сигез актриса уйный, дидегез, ә ничә ир-ат?

– Бөтен хикмәт тә шунда шул, ир-атлар юк бу спектакльдә. Дөресрәге, алар сәхнәдә юк, ә хатын-кызлар, әлбәттә, ир-атлар турында сөйләшә.

– Сез режиссерлар белән аралашасыздыр бит, алар ни ди соң? Нәрсә кызыксындыра аларны?

– Аралашам, әлбәттә! Әлмәттәге премьерага Чаллыдан Фаил абый Ибраһимов килгән иде. Булат Бәдриев куелышындагы спектакльне карагач: «Бик үзенчәлекле пьеса бит бу, аңа әле тагын бер генә дә, ике генә түгел режиссер борыннарын канатачак. Маладис, Булат! Җиңгәнсең!» — диде. Беләсезме, хикмәт нидә, минемчә? Бер тәнкыйтьчедән, яза башлаган гына заманаларда, «әсәрләреңдә подтекст юк» дигәнне ишетергә туры килгән иде. «Сигезле бию»дә исә подтекст өстендә подтекст һәм аны бит әле табып, аңлап бетерү генә җитми, актер уены аша тамашачыга да җиткерергә кирәк, менә шул катлаулы максат булуы җәлеп итәдер, күрәсең, режиссерларны.

– Равил әфәнде, ә ни өчен татар матбугатында сезнең исем бер дә күренми?

– Татар-газета журналларына башка язмыйм, дигән нәзерем юк анысы… Тик ул үзеннән-үзе ничектер шулай килеп чыкты: «Татарстан яшьләре»ндә эшләгән җирдән Чаллы хакимияте матбугат үзгендә эш тәкъдим иттеләр. Аннары Чаллыда чыга торган урыс телле газетага чакырдылар. Алга таба республика күләмендә нәшер ителә торган шулай ук урыс телендә чыга торган газетаның Чулман арьягы төбәгендәге үз корреспонденты булу тәкъдиме килде, тора-бара бюро төзеп, шуның эшен җайга салырга кирәк булды. Ә 2015 елның ноябрендә «Татнефть» компаниясенә «Нефтяные вести» газетасының мөхәррире итеп эшкә чакырдылар. 20 ел эчендә мин фәкыйрегез нибары бер мәртәбә генә татар матбугат органына кызыклы булдым, «Татмедиа»ның Чаллыдагы бер филиалына директор булып килмәссеңме икән, дип, Казаннан шалтыраттылар. Тик ул чакта, кем әйтмешли, поезд киткән иде инде, мин Әлмәткә күченгән идем.

– Спектакльгә кире кайтсак, ни өчен ул кече залда уйнала? Зурысын тамашачы белән тутырып булмас, дигән курку бармы әллә?

– Юк, хикмәт бөтенләй аңарда түгел. «Сигезле бию» — урысча әйткәндә, «камерный», «атмосферный» спектакль. Ул кешеләр күңеленең иң тирән төпкелләренә үтеп керергә тиеш, ә моның өчен тамашачының артистларга якын урнашуы кирәк. Форсаттан файдаланып, барлык дусларымны, таныш-белешләрне спектакльгә чакырам. Килегез, үкенерлек булмас!

Кайда син, маймыл бабай?

Соңгы вакытта шәҗәрә төзү модага кереп китте һәм... шундыйрак бер нәрсә ачыкланды – барлык татар кешесенең дә нәсел җебе теге яки бу күренекле шәхескә барып тоташа икән. Тарихи шәхес оныгы булуның шундый җиңел нәрсә икәнен белгәч, мин дә шәҗәрә төзергә булдым.

Марат КӘБИРОВ

Барысыннан да уздырырга иде исәп: «Кешегә әйләнгән беренче маймыл минем дәү әти булган!» – дип әйтергә. Һәм тарихта эз калдырган бөтен кешене дә үзебезнең нәселгә кертеп бетерергә... Тик берни дә килеп чыкмады.

* * *

1859 елның ноябрендә Чарльз Дарвин үзенең шаккатыргыч теориясе белән чыгыш ясый – бар тереклек табигый сайланыш нәтиҗәсендә барлыкка килгән. Кеше хакында бер сүз әйтелмәсә дә, нәтиҗә аермачык.

Һәм Дарвин мизгел эчендә Кешене Ходай яралткан илаһи зат булудан туктатып, маймыл дәрәҗәсенә төшереп куя. Әлбәттә, яратмыйлар инде Дарвинны. Хәтта һәртөрле эзәрлекләүләргә кадәр барып җитәләр. Үзегез яратыр идегезме соң берәрсе сезне маймыл оныгы дип әйтсә?

Һәр яңалык ул – бер ахмаклыкның икенче ахмаклык белән көрәшүе. Һәр яңалык озак еллар буе яшәп катып калган, туң калыпка әйләнгән ахмаклыкны җиңеп чыга да... бераздан үзе бер калыпка әверелә. Монда да шулай: халык ахмаклыгын Дарвин ахмаклыгы җиңеп чыга... Шуңа күрә бүген хәтта бот буе баладан сорасаң да, күкрәген киереп: «Кеше маймылдан яралган!» – дип чатнатып җавап бирә. Бер икеләнүсез, бер шиксез. Тулы ышаныч белән. Үзе карап торган диярсең.

Нәрсәгәдер ышану кешенең кимчелеге түгел. Ул – кешегә үз-үзен саклау өчен табигать тарафыннан бирелгән калкан. Һәр белем – яңалык, һәм һәр яңалык – куркыныч: ул кешене күнегелгән тигезлектән, стабильлектән чыгара. Гади генә мисал, әйтик, сез хәләлегезнең сөяркәсе барлыгын белдегез. Һәм – бетте! Тормышыгыз челпәрәмә килде. Ә белмәсәгез, элеккечә бәхетле булып, тату гына итеп тотанаклы тормышта яшәр идегез әле. Берни дә үзгәрмәс иде. Ә белгәч – булмый. Белем – куркыныч нәрсә, ул тормышның астын өскә китерергә мөмкин. Ә белмәс өчен уйламаска, эзләнмәскә, тикшермәскә, ишетмәскә, күрмәскә кирәк. Бары тик башкалар әйткән сүзгә ышанырга.

Кешеләрнең, тоташ халыкларның нәрсәгәдер берсүзсез ышануы ул наданлык та, ахмаклык та түгел, ә нибары ирешелгән тотанаклылыкны җуярга теләмәү генә. Бер карасаң, чынлап та шулай ич инде. Маймылдан яралдыни, кызыл балчыктан ясалдыр ни – хаҗәте юк, буласы булган бит инде... Иң мөһиме: сугыш чыкмасын да армиягә алып китмәсеннәр, югыйсә кредитыңны ничек түләрсең.

САКАЛЛЫ КЕШЕ ЯЗМАЛАРЫ

Ләкин адәм балалары арасында белемнән курыкмаучылар да бар. Һәм алар гасырлар аша Дарвинга болай дип кычкыралар: «Әй, абзый, аңлашылып җитми торган җирләр күп бит синең бу нәрсәңдә. Әллә килеп төшендереп китәсеңме?» Дарвин дәшми. Аны да гаепләп булмый инде: карт булгач, колагы да ишетми торгандыр, ара да ерак бит.

Ә галимнәр баш вата: маймылның кешегә әйләнү процессы ничек булган соң? Беркемнең дә моны аңлатырлык дәлиле юк. Һәм «Homo sapiensның ни рәвешле барлыкка килүе бүген дә палеонтологиянең иң бөек сере булып кала» (Роджер Левин)

4,6 млн ел эчендә маймыл туры атлаучы кешегә (Homo erectus) әверелә.

Шуннан 1 миллион ел эчендә Homo sapiens дигән аңлы затка әйләнә.

Һәм шуннан соң 200 мең ел (!) эчендә космоска очу дәрәҗәсенә ирешә.

«Кешелекнең мондый сикерешe эволюция була алмый, бу революция була, – ди биолог Томас Хаксли. – Ә бит төрләрнең сизелерлек үзгәреше өчен унар миллион ел таләп ителә.»

Һәм тагын бер нәрсә.

Эволюция нәтиҗәсендә адәм баласы бүгенге кыяфәткә кергән. Ул кулына таш, таяк алган, шуның нәтиҗәсе буларак, бармаклары үскән. Бернәрсәгә дә хаҗәте булмагач, койрыгы юкка чыккан. Икенче төрле әйтсәк, яшәү өчен көрәштә кеше үзен уратып алган тормышка яраклаша. Көнкүреш өчен мөһим органнары һәм сыйфатлары камилләшә, ә кирәксезләре юкка чыга. Без шушы фикерләр нигезендә тәрбияләнгәнбез. Эволюция теориясе шуны сеңдерә: «Табигать бер генә төргә дә көндәлек җан асрау өчен мөһим булганнан артык сәләт бирми» (Альфред Уоллес, биолог).

Кешенең иң үсешкә ия һәм иң катлаулы әгъзасы – баш мие. Ул бүгенгә кадәр тиешенчә өйрәнелеп бетмәгән. Баш миенең мөмкинлекләре чиксез. Адәм баласына шулкадәр акыл сәләте ни өчен кирәк булган соң? Исән калу өченме? Көнкүреш өченме? Ә бит ул бу сәләтенең яртысын да кулланмый диярлек.

Чарльз Дарвинның партнеры Альфред Уоллес моны түбәндәгечә аңлата: «Андый корал (баш мие) кешенең киләчәктәге ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен кирәк».

Әгәр чынлап та шулай икән, ник ул баш мие Homo sapiens дигән төрнең исән калуы өчен күпкә мөһимрәк булган төнлә да күрү, ис сизү, ерактан ишетү кебек сәләтләрне ныграк үстерүгә булышлык итмәгән? Ә аучылык, игенчелек белән шөгыльләнгән кыргый кешегә җан асрау өчен бик үк мөһим булмаган сәнгати һәм фәнни сәләтләр чамасыз зур үсеш алган?

Тел феноменын да шушы өлкәгә кертергә мөмкиндер. Кешенең көнкүреше өчен берничә аваз җитә. Ә сөйләшү механизмы үтә дә катлаулы...

Әлбәттә, моны ниндидер рухи ихтыяҗлар белән бәйләргә мөмкин. Әмма тереклекнең бер генә төрендә дә рух төшенчәсе барлыгын белмибез. Изгелек тә, гаделлек тә, намус та табигать өчен ят нәрсә. Җан асрау һәм табигый сайланышта җиңеп чыгу өчен боларның берсе дә кирәкми.

Әгәр кеше маймылдан яралган икән, аның йоны ни өчен коелып беткән? Бу сорауның ахмак икәнен үзем дә чамалыйм инде. Ашыкмый торыйк әле. Йон ни өчен кирәк? Иң беренче чиратта, тән җылысын саклау өчен. Һәм әлбәттә, чебен-черки h.б. вак-төяк бөҗәкләр бимазаламасын өчен дә. Инглиз зоологы Десмонд Моррис Homo sapiensны 4237 төрле сөтимәр белән чагыштырып карый. Тәне йон белән капланмаган сөтимәрләр бары тик җир астында (тән җылысын саклауга мохтаҗлыклары юк) яки суда яшәүчеләр (тәннең шудырмалы булуы әһәмиятлерәк) һәм панцирьлылар гына булып чыга. Бу җәһәттән дә кеше – бердәнбер. Һәм аның ялангачлыгын эволюция кануннары белән аңлатып булмый.

Шулай итеп, Дарвин теориясе Җирдәге тереклекнең эволюцион үсешен аңлатуда чиксез зур әһәмияткә ия булса да, кешенең килеп чыгышын тулысынча исбатлый алмый. Һәм «кеше маймылдан яралган» дип тулы ышаныч белән әйтү мөмкин түгел.

Кеше каян барлыкка килгән соң? Моны бүген бер кеше дә белми бугай. Диниләрдән башка, әлбәттә. Хәер, анысы соңрак...

«Татарстан 24»: тәүлек буе яңалыклар

«Эфир» белән «Казан» телекомпанияләре берләштерелеп, яңа барлыкка килгән «Татарстан 24» каналы 7 февральдә «челтәр» тарихын башлап җибәрде.

Дилбәр ГАРИФУЛЛИНА

«ТАТМЕДИА» составындагы район телекомпанияләре дә яңа каналның территориаль бүлекләре булачак. Телеканалның иң беренче партнеры исә – Яшел Үзәндәге «Зеленый Дол» телеканалы. Җәй башына республиканың барлык эфир телеканаллары «Татарстан 24» бренды астында эшләячәк. «Татар-информ» мәгълүмат агентлыгында узган матбугат очрашуында «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте генераль директоры Андрей Кузьмин билгеләп узганча, район каналлары өчен «Татарстан 24» белән «челтәр» килешүе төзү – отышлы вариант, бу аларга югалып калмаска булыша, реклама биреп, акча да эшли алачаклар.

– Каналның иҗади концепциясе дә үзгәрә. Телеканалда хәбәрләр татар һәм рус телләрендә бара, без ике теллелек принцибын саклап кала алдык, – диде Андрей Кузьмин.

«Мәгълүмат чаралары турында»гы федераль законадагы үзгәрешләр нәтиҗәсендә, 20 түләүсез федераль телеканал пакеты билгеләнгән. Аларның һәрберсенә билгеле бер кнопка бирелгән. Телеканалларның контентында җирле программалар чыкмаячак. Шуңа да «Татарстан 24» гомумреспублика челтәрле канал булдыру идеясе туган. Ул пультның 22нче кнопкасында булачак.

Яңа каналның төп концепциясе – тәүлегенә 24 сәгать эшләп, һәр сәгать саен республика яңалыкларын биреп бару. Телеканалда хәбәрләр татар һәм рус телләрендә бара. Телеканалның генераль директоры Сергей Лобов әйтүенчә, каналның потенциаль аудиториясе – 3 800 000 кеше, ягъни бөтен республика халкы. Аудиториясе – район һәм шәһәрләрдә яшәүчеләр югары белемле актив тормыш алып баручылар.

– Телеканалда һәр сәгать хәбәрләрдән башлана. Аларның 80 проценттан артыгы республика районнарыннан. Максатыбыз – Казан белән генә чикләнеп калмыйча, район яңалыклары, анда булган вакыйгалар белән дә таныштырып бару. Шулай ук мәгълүмати, аналитик, иҗтимагый-сәяси, фәнни-популяр тапшырулар да күп. Канал эфирына интервьюлар да чыга, экспертларның фикерләре белән дә таныштырып бара. Үз телепродукциясе 90 процентны алып тора, – диде журналистларга Сергей Лобов.

Хәзерге вакытта районнарда эшләүче журналистларның квалификацияләрен күтәрү буенча эшләр алып барыла. Шуның нәтиҗәсендә, контент тагын да сыйфатлырак булыр дип көтелә.

vk.com

Ленар Зарипов:

«Яңача пешерелгән бер кәтлит тә гаилә тормышына яңа төсмер кертә»

Казан егете Ленар Зариповның ашарга пешерүгә карашы үзенчәлекле. Аның өчен ул – гаиләләрне, дусларны, туганнарны тагын да якынайту чарасы. Озак еллар Казан рестораннарында шеф-повар булып эшләгәннән соң, Ленар хәзер башкаларны өйрәтә башлаган. Пешкченең аш бүлмәсендәге серләре белән без дә якыннанрак танышып кайттык.

Алисә САБИРОВА

– Гадәттә, көчле затлар ашарга пешерүне хатын-кыз эше буларак кабул итә. Ә сез бу һөнәрне ничек сайладыгыз?

– Гаиләдә без ике малай үстек. Мин кечкенәдән өй эшләрендә әнигә булыша идем. Аш-су әзерләгәндә дә уң кулы булдым. Мәктәптән соң сәүдә-икътисад көллиятенә укырга кердем. Соңыннан Казан кооператив институтында технолог һөнәрен үзләштердем. Югары белем кешеләр белән идарә итү, үз эшеңне башлап җибәрү өчен кирәк булды. Практика вакытында остаз шеф-поварларым яхшы булды. Иренмәделәр, өйрәтү өчен күп көч һәм вакыт сарыф иттеләр. Казанның төрле рестораннарында эшләп тәҗрибә туплагач, мастер-класслар бирә башладым.

– Кешеләр, аеруча хатын-кызлар болай да күп вакытын аш бүлмәсендә үткәрә. Акча түләп ашарга пешерергә өйрәнүчеләр дә табыламы?

– Без нинди дә булса бер ризыкның рецептын бирмибез. Кулында рецепт булса, кеше: «Берәр ингредиентын онытмасам ярар иде», – дип борчыла башлый. Күбрәк белем һәм технологияләрне бирергә тырышабыз. Ашарга пешерү тамак туйдыру чарасы гына түгел. Бергә әзерләгәндә, гаилә әгъзалары аралаша, дуслаша, тагын да якыная. Дәресләргә аеруча балалар яратып йөри. Аш-су өлкәсендә инде зур тәҗрибәсе булган хатын-кызлар да очрый дәрестә. Мәсәлән, бер ханымның яраткан кәтлит рецепты бар иде. Мин аңа бераз үз киңәшләремне бирдем. Гаиләдәгеләр бу үзгәрешне шунда ук сизеп алганнар. Яңача пешерелгән бер кәтлит тә гаилә тормышына яңа төсмер, ялкын кертергә мөмкин.

– Сез нинди кухняга өстенлек бирәсез?

– Миңа үз традицияләренә тугры калган кухня ошый. Италия, Франция кухнясы үз үзенчәлеген саклаган. Мәсәлән, шул ук Европада пешерелгән ризыкларны үз илендә һәм бездә ашап карасаң, җир белән күк арасы. Анда ингредиентлар бүтән бит. Бездә татар милли ашлары бик үсмәгән әле, чөнки буыннан буынга белем калдыру дигән гадәт юк. Милли кухня шулай югала инде ул. Республикада туризмны үстерүдә милли ризыкларның да өлеше зур бит. Ризыкта милли-мәдәни мирас сакланган. Хәзерге вакытта күп кеше өчен татар ашлары өчпочмак, бәлеш, чәк-чәк белән чикләнә. Язучы Рабит Батулла татар ашлары турындагы кулъязмалары белән уртаклашты. Шунда татар милли ризыклары турында бик күп кызыклы фактларга тап булдык. Мәсәлән, без хәзер яратып ашый торган бавырсак элек иттән ясалган булган. Аны ерак җирләргә киткәндә әзерләгәннәр. Ә чын татар чәен кем әзерли хәзер бездә? Элек безнең әби-бабайлар мичтә пешерелгән ризык ашаган, бу да бит үзенчә ризыкның файдасын саклап калу өчен кирәк. Милли кухня буенча башкарасы эш, өйрәнәсе материал күп әле.

– Чын татар чәе нинди була соң?

– Кайнатылган суда чәйне төнәтеп, шуңа күп итеп сөт салабыз. Плитәдә кабат җылытып алабыз. Чәшкәгә салганда бер чеметем тоз, ак май өстибез. Бик тәмле, ә иң мөһиме: файдалы чәй.

– Сезнеңчә, традицияләрне саклап калган иң тәмле милли татар ашларын Казанда кайда пешерәләр?

– Татар ашларын пешерүче рестораннар күп, ләкин аларда, гадәттә, катнаш кухня. Ә гомумиләштереп карасаң, иң яхшы ресторан өйдә ул. Әниең, тормыш иптәшең пешергән ризыклардан да яхшырак ни булсын?! Һәр ресторанның ашарга пешерү буенча үз нормалары, стандартлары бар. Шуңа да тәм, традиция икенче урында кала. Ә өйдә яратып, күңел җылысын биреп пешерәләр. Аннан соң ризык исе булган өйгә ир-атның да һәрвакыт кайтасы килеп тора.

– Ир-ат йөрәгенә юл ашказаны аша, дип тә әйтәләр бит әле...

– Ир йөрәгенә генә түгел, хатын-кыз йөрәгенә дә юл ашказаны аша. Үз тәҗрибәмдә сынадым. Иң мөһиме: күп түгел, ә тәмле булсын. Бездә ризыкны тәлинкәгә тутырып салырга яраталар. Ашказанының өчтән бер өлеше – су, шуның кадәрле ризык, калганы һава белән тулырга тиеш. Ирнең тамагы бераз булса да ач калсын. Өстәл артыннан түгәрәк корсак белән торып китмиләр. Әгәр сез ашарга пешерү өлкәсендә әле яңа кеше икән, үзегез иң оста пешергән берәр ризыктан башлагыз. Аны төрләндерегез. Шунысы да бар: зур кисәкле, күп ризыктан тамак тиз туя, авыз аның тәмен тоймый башлый. Шуның өчен табында аз-азлап төрле ризык булсын. Өйдәге атмосфера да яхшы кәефкә йогынты ясый. Ароматерапия дигән әйбер дә бар бит әле. Романтик кичке аш вакытында иң мөһиме шуны онытмаска кирәк, егет сезнең янга ашарга түгел, ә аралашырга килә. Табын артында аңарда «болар барысы да минеке, мин моны көн саен күрергә телим» дигән теләк тусын. Шуңа да алдан ук нәрсә турында сөйләшәчәгегезне уйлап куегыз, тышкы кыяфәтегез турында да онытмагыз.

– Бөтен хатын-кызларның да башын авырттырган сорау – ничек төрләндерергә?

– Кечкенә ашка балык пешерү яхшырак. Башка ит ризыкларына караганда, организм өчен ул җиңел. Мәсәлән, сибас балыгын тәңкәсен чистартмыйча гына пешереп була. Сатып алганда ук саңакларын һәм эчен чистартуларын сорагыз. Пешерер алдыннан балыкны эре диңгез тозы белән тозлагыз. Табаны да, балыкны да майлагыз. Тәңкә ярдәмендә балык дымын югалтмый, тәмен саклап кала. Бу балык янына бәрәңге дә, ярмалар да куярга ярамый. Парда пешкән яшелчәләр яки соус белән бизәсәң отышлырак. Бик тәмле соус өчен зәйтүн мае, сарымсак, тоз, лимон согын аласың да кушып болгатасың. Берничә сәгатькә суыткычка куясың. Җәй көне сарымсакның яшь орлыкларыннан (сарымсак башы) ак май, тоз салып тәмле соус ясасаң да була. Аны да, табынга куйганчы, берничә сәгать суыткычта тотарга кирәк.

– Ә шеф-повар үзе нинди ризыклар ашарга ярата?

– Мин тәмле, ләкин мәшәкать тудырмый торган ризыклар яратам. Итне дә чәйнәргә кирәк, ул да авыр әле. Ләкин бәрән итен бик яратып ашыйм.

– Өегездә аш бүлмәсендә кем хуҗа?

– Кем өйдә – шул хуҗа. Әни дә, хатын да, үзем дә пешерәм. Бездә «бүген син дежур» дигән нәрсә юк. Барыбыз да ашарга пешерергә ярата.

Рәхәтләнеп елмаерлык булсын!

Бүген – Халыкара стоматологлар көне. Шул уңайдан без теш чистарту культурасы, авыз куышлыгы авырулары, стоматология өлкәсендәге яңалыклар турында теш табибәсе Рузилә ХАННАНОВА белән сөйләштек.

Зөһрә САДЫЙКОВА



– Рузилә Салаватовна, тешләрне һәм авыз куышлыгын ничек дөрес итеп чистартырга һәм тәрбияләргә кирәк?

– Мин авырулар арасында «тешләрегезне ничек чистартасыз?» дигән сораштыру уздырам. Һәм шуларга анализ ясаганда, балачактагы гадәтләр күпчелек кешедә дөрес формалашмаган, дигән нәтиҗәгә киләм. Халыкның 60-70 проценты тешләрен иртәнге аш алдыннан чистартулары турында әйтә, чөнки моңа безне әти-әниләр балачактан ук өйрәтә. Һәм ул кеше аңында гадәт булып формалаша. Чынлыкта исә безнең максат – тешләрдәге ризык калдыкларын алу. Аңлашыла инде, бу эшне ашаганнан соң эшләргә кирәк. Тешләрне иртә-кич чистарту тагын да яхшырак.

– Кулланучылар базарында нинди генә теш пасталары һәм щёткалары юк. Алар арасында иң яхшысын ничек сайларга?

– Дәвалау-профилактика өчен каралган теш пасталары фторлы һәм кальцийлы була. Татарстанлыларга составында фтор булган теш пасталарын сайларга киңәш итәм. Теш уртлары белән проблемалары булганнарга ялкынсынуга каршы чаралар куллану файдалы. Теш щёткасын сайлауга килгәндә, балаларга – йомшак, әлкәннәргә уртача катылыктагыларын алырга кирәк. Әгәр тешләргә ташлар (зубной камень) еш җыела торган булса яки каты итеп чәй һәм каһвә эчәргә яратучыларга щётка용 катылыгын да алырга мөмкин. Болардан кала, теш авыруларын профилактикалау өчен теш җепләре, ершиклар һәм чайкагычлар файдаланырга мөмкин.

– Ләкин тешләрен дөрес тәрбияләп торган кешеләрнең дә күпчелеге аларның сау-сәламәт булуы белән мактана алмый бит.

– Шулай да тешләрне дөрес итеп чистартсак, авыруны булдырмый калдырырга яки кичектереп торырга мөмкин. Кариес ничек барлыкка килә? Микроорганизмнар бүлеп чыгарган сөт кислотасы эмальне «кимерә» башлый. Шул өлештә кариес барлыкка килә. Бу эмальдә ак тап булып «урнаша». Әгәр без вакытында тешләрне дөрес тәрбияләсәк (ныгытучы гельләр кулланcак), эмаль кабат төзәлә, ягъни кариеска тирәнәергә урын калдырмый. Димәк, тешләрдәге ризык калдыкларын алу кариесны булдырмый калырга ярдәм итә.

– Ә гельләрне нинди ешлык белән кулланырга кирәк?

– Әгәр бер үк тешне бер ел эчендә берничә тапкыр дәваларга туры килсә, составында кальций булган гельләрне ике ай саен кулланырга кирәк. Аннан азрак табибка мөрәҗәгать иткән очракта, составында фтор булган гельне ярты елга бер тапкыр куллану да җитә.

– Кариестан кала, тагын нинди теш авырулары бар?

– Кариес ул – теш кимчелеге. Табиблар аны дәвалый, ямый, ягъни инфекция белән көрәшә. Әгәр бу вакытында дәваланмаса, инфекция нервыга китә. Монысы пульпит дип атала. Аннан да яманрагы сөяк тукымасына киткән авыру – пародонтит. Теш урты авырулары пародонтит дип атала.

– Кайбер кешеләр теш уртларының сизгерлегеннән зарлана.

– Аның сәбәпләре төрле булырга мөмкин: кариес, тешләрнең ышкылып, «юылуы», шулай ук артык йөк килү дә сизгерлекне көчәйтергә мөмкин.

– Рузилә Салаватовна, стоматология бер урында гына тормый. Хәзер бу өлкәдә нинди яңа төрле процедуралар кулланыла? Мәсәлән, соңгы вакытта аеруча популярлашкан тешләрне агартуга карата сез нинди фикердә?

– Тешләрне агарту – дәвалау чарасы түгел. Бу эстетик стоматологиягә карый. Уңай яклары дигәндә, аңлашыла инде, бу – матурлык, елмайганда үзеңне иркен хис итү. Әмма һәр процедураның кимчелеге бар. 18 яше тулмаганнарга тешләрен агартырга ярамый. Шулай ук пломба һәм коронкалары булганнарга да киңәш ителми, чөнки алар барыбер агармаячак. Аннан соң әлеге процедураны башкарыр алдыннан, теш авыруларын дәваларга кирәклеген дә истән чыгармау мөһим. Бу эшне өй шартларында да эшләп була. Әмма агарту системаларын сайлаганда, өстенлекне популяр булганнарга бирергә кирәк. Профессиональ системалар исә үзләренең катылыклары белән аерылып тора. Шулай ук хәзер тешләрне ультратавышлы скалер белән чистарту да модада. Монысы табиб күрсәтмәсе нигезендә, ярты елга бер тапкыр башкарыла.

– Тешләрне су көче ярдәмендә чистарту турында да ишеткән бар.

– Анысы өйдә махсус җайланма – ирригатор ярдәмендә чистарту. Көчле су агымы теш араларын яхшылап чистарта, уртларга массаж ясый.

– Тешләр авыртмаган очракта да табибка мөрәҗәгать итү мәҗбүриме?

– Авыруны дәвалауга караганда, аны булдырмый калу күпкә яхшырак. Шуңа күрә мин, һәр ярты ел саен табибка күренергә кирәк, дип киңәш итәм. Авыз куышлыгындагы күп кенә авырулар пациентның үзенә сизелмәскә дә мөмкин. Мондый тикшерүләр вакытында онкологик авырулар ачыкланган очраклар да бар. Шуңа күрә авыз куышлыгындагы йомшак тукымаларда (тел, яңак) озак төзәлми торган яралар, шешләр, тырналган урыннар булса, кичекмәстән табибка мөрәҗәгать итәргә кирәк.

– Әңгәмәбезне балаларның тешләренә карата булган сораулар белән дәвам итәсем килә. Аларның тешләрен ничә яшьтән чистарта башлау дөрес?

– Кагыйдә буларак, теш чыккач ук чистарта башларга кирәк. Ризык юшкыны сөт тешләренә дә, төп тешләргә дә бер дәрәҗәдә утыра. Сабыйларның тешләрен дә ярты ел саен табибка күрсәтергә кирәк, чөнки өлкәннәрдә очрый торган авыруларның барысы да кечкенәләрдә дә күзәтелә. Алар балаларда хәтта кискенрәк тә уза әле – тешләре тизрәк бозыла.

– Сөт тешләре дә шундый ук игътибар таләп итә, димәк? Кайбер әти-әниләр, сөт тешләре барыбер төшә, аларны дәваламасаң да ярый, дип уйлап ялгыша?

– Әйтүемчә, кариес ул – авыздагы инфекцияләр. Ә алар авырттыра, теш сызлавы иң көчле авыртулардан санала. Тешләр тиз һәм еш бозылган очракта, авыруның сәбәпләрен ачыкларга кирәк. Гигиена таләпләре тиешенчә үтәләме, организмда җитди үзгәрешләр юкмы – шуны тикшерергә. Шулай ук бавыр, бөер эшчәнлеге бозылу, шикәр авыруы да тешләрдә чагылыш табарга мөмкин. Сөт тешләрен дәвалау даими тешләр сәламәтлегенә һичшиксез зур йогынты ясый. Аларны вакытыннан алда алдыру даими тешләрнең дөрес урнашмавына китерергә мөмкин. Ризыкны дөрес итеп тешләп ашамау нәтиҗәсендә тешләргә көч килә. Ә бу киләчәктә хәлне катлауландырырга мөмкин. Шуңа күрә балачакта тешләргә, киресенчә, тагын да зуррак игътибар бирергә кирәк. Аннан соң балаларны теш профилактикасына өйрәтү өлкәннәргә караганда күпкә нәтиҗәлерәк.

ТЕШНЕҢ ДӘ ДУСТЫ БАР, ДОШМАНЫ БАР

Углеводлар кулланганнан соң, тешләрне чистартырга кирәк. Тешләрнең сәламәтлегенә ризыкның катылыгы-йомшаклыгы да йогынты ясый. Хәзер күпләр йомшак, чәйнәми генә йотыла торган ризыкларга өстенлек бирә, ә тешләр өчен каты, яхшы итеп чәйнәлә торган ризыклар ашау яхшы. Шуңа күрә стоматологлар каты яшелчә, җиләк-җимеш ашарга киңәш итә. Безнең төбәктә йод аз. Шуңа күрә йод профилактикасы турында да онытырга ярамый.

БЕЛӘСЕЗМӘ?

- **Без тешнең өчтән бер өлешен генә күрәбез. Калганы уртларда яшерелгән.**
- **Теш – кеше организмының яңадан үз хәленә кайта алмаган бердәнбер өлеше.**
- **Тешнең тышкы ягын каплаган эмаль – безнең организмның иң каты өлеше.**
- **Беренче теш щеткасы 1780 елда Англиядә уйлап табылган. Аның тоткасы – сөяктән, ә кыллары кабан йонынннан эшләнгән.**
- **Беренче теш пастасы биш мең ел элек мисырлылар тарафыннан, пемза һәм шәрабтан ясалган.**

